وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! *(Коръән, 3:103)*

6+

# ДИН вә Мәгыйшәт

№3 (236). МАРТ - 2015 / ҖӨМӘДИӘЛӘҮВӘЛ - ҖӨМӘДИӘЛАХЫР - 1436

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ

Газетада Аллаһы тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!




## АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ ЧЫДАМЛЫК, САБЫРЛЫК, ЯРДӘМ БИРСЕН

Март аенда Татарстан халкы олы хәсрәт кичерде. Казанның Киров районында урнашкан "Адмирал" сәүдә үзәгендә чыккан янгын дистәләгән кешенең гомерен өзде. 13 мартта, җомга намазыннан соң республика мәчетләрендә мәрхүм булганнар рухына Коръән укып, дога кылынды. Фаҗигадә гомерләре өзелгән мәрхүмнәрне искә алу, аларның туганнарының, якыннарының кайгысын уртаклашу уңаеннан төп чара Кол Шәриф мәчетендә үткәрелде.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин янгында мәрхүм булганнарның туганнарының, якыннарының кайгысын уртаклашты. "Сәүдә үзәгендәге янгында үлгәннәр хакында авыр хәбәрләр тарала тора. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән мәрхүмнәрнең туганнарының, якыннарының кайгысын уртаклашам, зыян күргәннәрнең тизрәк сәламәтләнүләрен телим. Без, догалар кылып, Аллаһы тәгаләдән шушы бәлагә таручыларга чыдамлык, сабырлык, ярдәм бирүен сорыйбыз. Раббыбыз, кайгыларга-борчуларга тарыганнарның хәлләрен азга гына булса да җиңеләйтсәң иде. Мондый фаҗигалар алга таба безне урап узсын, барчабызга тыныч яшәргә язсын иде", - диде мөфти.




3 бит

"Зәйтүнә" төбәкара мөнәҗәт фестивале яшьләрне дә, өлкәннәрне дә жыйды



## "ФРОНТОВИК ХАТЫ":

*"Без 11 е көнне Ярославль шәһәреннән чыгып киттек. Безнең барасы җир билгеле инде, аны сезгә әйтеп торуның кирәге юк. Шулай итеп, яшь йөрәкнең батырлыгын сынап карау өчен барабыз..."*

10 бит





"Дин вә мәгыйшәт" газетасын өйгә дә яздырып алырга була. Почта бүлекчәләренә мөрәҗәгать итегез. Индекс – 16046

# ТАТАРСТАН ДИН ӘҺЕЛЛӘРЕНЕҢ ЧИРАТТАГЫ ПЛЕНУМ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ

**Март башында Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең чираттагы күчмә пленум утырышы үткәрелде. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә узган җыелышта аның урынбасарлары, нәзарәтнең Голәмалар һәм Казыйлар шуралары әгъзалары, республиканың барлык районнары имам-мөхтәсибләре катнашты.**

Җыелышта Татарстан дин әһелләре дини эшчәнлек алып баруга кагылышлы шактый сорауларны уртага салып сөйләштеләр.

2015 елның ике ае Татарстан дин әһелләре өчен бик тыгыз үтте. Гыйнвар ае Мәүлид уңаеннан оештырылган дини чаралардан торды.

Моннан тыш ел башында мәдрәсәләр өчен уку-укыту стандартларын эшләү турында халыкка игълан ителде. Хәзерге көндә бу стандартлар, программалар төзү, дәреслекләр әзерләү буенча эш дәвам итә. Бу эштә мәдрәсә җитәкчеләре, мөгаллимнәре үзләре дә актив катнаша. Хәзер алар программа төзүчеләр исемлеген барлый. Май аенда мәдрәсәләрдә укытыла торган төрле дәреслекләрнең әзер программалары тикшерү узарга тиеш.

Ел башы тәҗрибә уртаклашуга да бай булды. Мөфти җитәкчелегендәге делегация Төркиядә булып кайтты. Сәфәр вакытында Төркиядәге бик күп дини оешмалар белән якыннан таныштылар. Үзара хезмәттәшлекне дәвам итү, уртак проектларны тормышка ашыру хакында сөйләшүләр корылды. Мәсәлән, иске кульязмаларны өйрәнү үзәген булдыру, аларда сакланып калган татар дин галимнәре китапларын үзебездә бастыру хакында фикерләр хуплау тапты.

Шуны да әйтергә кирәк, авыллардагы борынгы мәдрәсәләргә, аларда эшләгән гыйлем ияләренә, танылган дин белгечләренә игътибарны арттыру максатыннан чаралар үткәрелә башлады. Әйтик, Балтачның Кариле авылындагы мәдрәсәгә 300 ел тулу уңаеннан бәйрәм үткәрелде. Утыз Имәни белән бәйле Нурлат районы Кизләү авылында беренче тапкыр "Кизләү укулары" оештырылды.

Җыелышта төп мәсьәләләрнең берсе буларак, Голәмалар шурасы составы каралды. Мөфти Камил хәзрәт: "Башка илләрдәге Голәмалар шураларының фәтва чыгару юнәлешендәге тәҗрибәсе безгә эшчәнлекне тагы да көчәйтү кирәклеге турында сөйли", - дип ассызыклады.

Алга таба Голәмалар шурасы эшчәнлеген үзгәртү күз алдында тотыла. Көн дәвамында сорауларны җыеп, адреслы җавап әзерләп җибәрүне оештыру ниятләнелә. Катлаулы сорауларны исә Голәмалар шурасы әгъзалары үзләренең җыелышларында тикшерәчәк. Халык белән элемтәне тагын да арттыру өчен darulifta.tatar сайты эшләячәк. Биредә гомуми сораулардан тыш, шәхси сораулар бирү мөмкинлеге дә булачак. Җаваплар исә шәхси e-mail га җибәреләчәк. Бу яңа адымнар Голәмалар шурасы эшчәнлегенең дәрәҗәсен дә, нәтиҗәлеген дә арттырыр дип көтелә.

Утырышта шулай ук, мөфтинең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батровның, мөфти урынбасарлары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин һәм Рәфыйк хәзрәт Мөхәммәтшинның, "Зәкят" фонды җитәкчесе Илнур Вәлиев, ТР Фәннәр академиясе иҗтимагый фикер һәм ислам өйрәтүләре бүлеге җитәкчесе Сәет-Дамир Шәһәвиевның чыгышлары тыңланды.



# "НӘЗАРӘТ ВӘКИЛЛӘРЕ ПЕРМЬДӘ "МӨСЕЛМАН ДӨНЬЯСЫ" ДИП АТАЛГАН ФОРУМДА КАТНАШТЫ

**Пермьдә "Мөселман дөньясы" дип аталган форум узды. Әлеге төбәктә бу чара инде бишенче ел рәттән үткәрелә. Форумның төп максаты - халыкны ислам дине белән таныштыру, аның мәдәнияте, бай мирасы турында мәгълүмат җиткерү, ислам диненең традицияләрен һәм бәйрәмнәрен барлау. Милләтара һәм дини мөнәсәбәтләрне ныгыту, шулай ук, иң әһәмиятле бурычларның берсе булып тора.**

Чарада катнашучыларны Татарстан мөфтие исеменнән нәзарәтнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров сәламләде. Нияз хәзрәт Татарстан мөфтияте тарафыннан дини мирасны торгызу һәм халыкка җиткерү өчен башкарылган эшләр хакында сөйләде.

Форум кысаларында мөселманнарга багышланган күргәзмә оештырылган иде. Ел саен әлеге күргәзмәдә 19 төбәктән мөселманнар тормышы белән бәйле экспонатлар урын ала. Күргәзмәдә ТР МДНнең "Хәләл" комитеты һәм "Хузур" нәшрият йорты да катнашты.




## Чаллының "Ак мәчет" мәдрәсәсенә Төркия мөгаллимнәре килде

**Чаллының "Ак мәчет" мәдрәсәсендә "Иҗтимагый процессларда тотрыклылыкны саклауда исламның роле" дигән темага халыкара фәнни-гамәли конференция уздырылды. Әлеге чараны КФУның Чаллыдагы филиалы, Чаллы социаль-педагогика технологияләре һәм ресурслары институты, "Ак мәчет" мәдрәсәсе уздырды.**

Конференциядән соң ике көн дәвамында Төркиянең Адыяман университеты галимнәре, ислам фәннәре факультеты өлкән укытучысы Мостафа Гүвәт һәм икътисад һәм административ фәннәр факультеты деканы урынбасары Мурат Әйан "Ак мәчет" мәдрәсәсе шәкертләренә дәресләр үткәрделәр. Дәресләр гарәп телендә барды. Мәдрәсә мөгаллимнәре татарчага тәрҗемә итте. Шулай ук фикер алышу, тәҗрибә уртаклашу ниятеннән түгәрәк өстәл уздырылды.



# ТӨРЛЕ ТӨБӘК МӨСЕЛМАННАРЫ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ИТҮ ТУРЫНДА КИЛЕШТЕ

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Камил хәзрәт Сәмигуллин, ай дәвамында төрле төбәк мөселманнары лидерлары белән очрашып, ике арада хезмәттәшлек хакында килешүләргә кул куйды.** Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Иваново өлкәсе мөселманнары Диния нәзарәте арасында төзелгән килешү нигезендә үзара тәҗрибә уртаклашу, дини уку йортларын әсбаплар белән тәэмин итү, якшәмбе мәктәпләрен оештыру, "хәләл" индустриясен үстерү һәм башка юнәлешләрдә хезмәттәшлек итәргә ниятләнелә.

***

**Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Казахстан мөселманнары Диния нәзарәтенең уку-укыту бүлеге җитәкчесе Бахтыбай Бейсенбаев һәм Мисырның "Нур Мөбарәк"** ислам мәдәнияте университетының уку-укыту бүлеге җитәкчесе Али Әлмөхәммәт белән очрашуда сүз Казахстан белән Татарстан диния нәзарәтләре арасында мәгариф һәм фән өлкәсендә хезмәттәшлек кору турында барды. Камил хәзрәт кунакларны Татарстан мөфтияте эшчәнлеге, проектлары белән таныштырды, мәдрәсәләр турында сөйләде. Шулай ук имамнар гыйлемен күтәрү буенча оештырылган укулар һәм уку әсбаплары, дини китаплар нәшер итүче "Хузур" нәшрият йорты хакында җиткерде.

Кунаклар сәфәр кысаларында мәдрәсәләрдә, мәчетләрдә булып, укыту тәртипләре белән якыннан танышытылар.

***

**Мөфтияткә Красноярск крае мөселманнары мөфтие Гаяз хәзрәт Фәтхуллин килеп китте.** Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Гаяз хәзрәтне нәзарәт эшчәнлеге белән таныштырды. Шулай ук Татарстандагы дини вәзгыять турында сөйләде, яңа уку елыннан мәдрәсәләргә кертелә торган уку-укыту стандартлары хакында аңлатты.

Очрашуда Татарстан һәм Красноярск мөфтиятләре арасында хезмәттәшлек итү хакында килешенде.

# МӨФТИ ЧИРМЕШӘН МӨСЕЛМАННАРЫ БЕЛӘН АРАЛАШТЫ ҺӘМ КОРЪӘН ХӘТЕМ ЧЫГУДА КАТНАШТЫ



***Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Чирмешән мөселманнары белән очрашты. Район мәдәният йортында уздырылган чарага авыл имамнары, актив мөселманнар, абыстайлар, мөгаллимнәр җыелды. Шулай ук район башлыгы Фердинат Дәүләтшин да килгән иде.***

Район җитәкчесе мөфтият белән район хакимияте арасында алып барылган нәтиҗәле хезмәттәшлек өчен мөфтигә рәхмәт сүзләрен җиткерде. Дин әһелләренең һәм җитәкчеләрнең үзара аңлашып эшләве мөселманнарга кагылышлы күп кенә сорауларны вакытында хәл итәргә ярдәм итүен билгеләп узды.

Камил хәзрәт үзенең чыгышында имамнарның бердәм булып, бер фикергә килеп эшләүләре, динебезгә хезмәт итүләре мөһим булуны ассызыклады. Мәгълүм булганча, нәкъ шушы нияттән нәзарәт белгечләре дини йолалар тәртибен әзерләп, имамнарга таратты. Авылларда дини эшчәнлек алып баруга ярдәмлек буларак "Шура" журналы нәшер ителә.

Камил хәзрәт Голәмаләр шурасы эшчәнлегенә тукталды. Озакламый һәркем үзен кызыксындырган дини сорауны бирә алсын өчен махсус сайт эшли башлаячагын хәбәр итте.

Мөфти Чирмешән районы имамнарына дини эшчәнлек алып баруда зур тырышлык куйганнары өчен рәхмәтен җиткерде. Биш муллага нәзарәтнең Рәхмәт хатларын тапшырды.

Район имам-мөхтәсибе Минсәгыйрь хәзрәт Миншин сүзләренә караганда, бүгенге көндә районда 24 мәчет эшләп килә. Тагын бер мәчетне төзү эшләре башланган. "Әгәр элегрәк мәчетләргә җомга намазына 5-6 кеше генә җыелса, хәзер намаз укучылар саны артты. Даими рәвештә атна саен мәдәният йортларында берничә дини чара уздырыла, мәчетләрдә балалар өчен укулар, конкурслар оештырыла. Укуларны оештырырга абыстайлар бик булыша. Моннан тыш районда "Нурлы" Чирмешән" дип аталган дини газет та чыгарыла", - дип сөйләде мөхтәсиб.

Очрашу ахырында Камил хәзрәт мөселманнарның күп сандагы сорауларына җавап бирде. Аннары мөфти хәзрәтләре район җамигъ мәчетендә Коръән-хәтем чыгуда катнашты. Район үзәк мәчетендә март аенда һәм рамазан башланганчы Коръәнне тулысынча укып чыгу үзе бер үрнәк гадәткә әверелгән.

# ШӘКЕРТЛӘР ӨЧЕН ӘДӘБИ КОНКУРС

Россия ислам институты Татарстанның югары һәм урта уку йортлары шәкертләре арасында әдәби конкурс уздыра. Конкурс шәкертләрнең гыйлемен арттыру, талантлы мөселман яшьләрен берләштерү һәм аларга иҗади эшләрендә ярдәм итү максатыннан үткәрелә.

Өч этаптан тора:

1. Әдәби әсәрләрне җыю (27 февраль - 27 апрель, 2015).
2. Әдәби әсәрләрне барлау (28 апрель - 11 мая, 2015).
3. Конкурска йомгак ясау (15 мая, 2015).

Бәйгегә эшләр 27 апрельгә кадәр кабул ителә: lkriu@yandex.ru. Конкурс нигезләмәсе белән dumrt.ru сайтында танышырга мөмкин.

# ДИН ӘҺЕЛЛӘРЕ ӨЧЕН ГАРӘП ТЕЛЕ КУРСЛАРЫ ОЕШТЫРЫЛА

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Казан федераль университеты дин әһелләре (имамнар, мәчеттә эшләүчеләр, дини уку йортлары мөгаллимнәре) өчен әдәби гарәп теле буенча курс уздыра.

Укулар 2015 елның апрель-декабрь, 2016 елның февраль - декабрь айларында үткәрелә. Дәресләрне гарәп теле белгечләре уздыра. Укулар тәмамлангач КФУ таныклыгы бирелә. Курс түләүсез.

Тулырак мәгълүматларны Россия ислам университетында (Казан, Газ урамы,19; 318 кабинет) 26 мартта сәгать 19.00дә үткәреләчәк оештыру җыелышында белергә мөмкин.

## ИСЛАМ ЖУРНАЛИСТЫ БУЛЫРГА ТЕЛИСЕҢМЕ?

***Россия ислам институтының "Журналистика" юнәлешендә укырга теләүчеләр өчен КФУның Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара мөнәсәбәтләр институты базасында "Мөселман журналисты мәктәбе" ачыла.***

Әлеге проект абитуриентларны РИИга укырга керергә әзерләү, журналист һөнәре үзенчәлекләре белән таныштыру максатыннан оештырыла. Кызыксынучыларның электрон почтага (amy_17@mail.ru) язып яки телефон аша элемтәгә керүләре сорала - 89172635834.

Россия ислам институтында журналистларны инде 3 ел әзерлиләр. Быел бу юнәлештә укырга теләүчеләр өчен 15 бюджет урыны каралган.

РИИның кабул итү комиссиясе телефоны - (843)251-01-55, адресы: Казан, Газ урамы,19. Рәсми сайт: ***http://kazanriu.ru/.***

# "ЗӘЙТҮНӘ" ТӨБӘКАРА МӨНӘҖӘТ ФЕСТИВАЛЕ ЯШЬЛӘРНЕ ДӘ, ӨЛКӘННӘРНЕ ДӘ ҖЫЙДЫ

***ТР МДН, Бөгелмә мөхтәсибәте һәм Бөгелмә шәһәренең "Татар мәдәнияте үзәге" белән берлектә "Зәйтүнә" төбәкара мөнәҗәт фестивален уздырды. Фестиваль өченче ел рәттән оештырылды. Быел катнашучылар арасында республика районнарыннан гына түгел, Башкортстан, Оренбург якларыннан килүчеләр дә бар иде. Берничә номинациядә узган фестивальдә катнашучылар саны 90га җитте. Азнакай, Баулы, Ютазы районнары мөхтәсибләре һәм Мөслим, Яңа Чишмә, Лениногорск районнары мөхтәсиб урынбасарлары фестивальнең кунагы булды.***

Фестивальне Рөстәм хәзрәт Хәйруллин хәер-фатихасын биреп ачып җибәрде һәм ул мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның сәламнәрен ирештерде.

Фестивальдә Татарстан җөмһүриятенең атказанган һәм халык артисты, профессор Мингол Галиев жюри рәисе булды. Шулай ук чыгыш ясаучыларны көньяк-көнчыгыш төбәге казые Марат хәзрәт Мәрданшин, төрле конкурслар лауреаты, "Сорнай" ансамбле солисты Илгиз Шәйхразиев һәм ТР МДНнең яшьләр эшләре бүлеге җитәкчесе Айгөл Биктимерова бәяләде. Баллар куйганда катнашучыларның башкару осталыгы, мөнәҗәтләрне сайлый белүе, сәхнә костюмнары, үз-үзләрен тотышлары да бәяләнде. Бигрәк тә мөнәҗәтләрне тамашачылар күңеленә җиткерерлек итеп башкаруга аерым игътибар бирелде.




Фестиваль бәйгесе 6 сәгатькә сузылды. Татар халкы мөнәҗәтләре бәйгесе дипломнар, бүләкләр, "Хузур" нәшрият йортыннан китаплар, сертификатлар тапшыру белән төгәлләнде. Ахырдан фестивальне оештыруга матди ярдәм күрсәткән иганәчеләргә Рәхмәт хатлары тапшырылды.

**ФЕСТИВАЛЬ НӘТИҖӘЛӘРЕ**
**ЯЛГЫЗ БАШКАРУ**

7-12 яшьлекләр арасында:
1 - Илгизә Галиуллина (Зәй)
2 - Розалина Латыйпова (Кандра)
3 - Диана Галиева (Лениногорск)

12-18 яшьлекләр арасында:
1- Алсу Исрафилова (Мамадыш)
2- Нигъмәтулла Якубзода (Казан, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе)
3- Зөһрә Шакирова (Яңа Чишмә)

18 һәм 40 яшьлекләр арасында:
1- Лилия Җиһаншина (Казан)
2- Абдулвәли Мөселманов (Казан, РИУ)
3- Махфузолла Якубзода (Казан, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе)

40 һәм өлкәнрәк яшьтәгеләр арасында:
1- Нажия Талипова (Чирмешән)
2- Гөлгенә Авзалова (Бөгелмә)
3- Лилия Шәяхмәтова (Кандра)

Ансамбльләр
Яшьләр:
Рисалә (Яңа Чишмә)
Хәлил (Казан, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе)
Ишрак (Бөгелмә)
Өлкәннәр:
Тургай (Бөгелмә, Карабаш)
Хыял (Казан, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе)
Хәзинә (Башкортстан, Кандра)

**Хөрмәтле мөселман кардәшләр! Гомәр бине Хаттаб (радияллаһу ганһү) мондый риваять тапшыра: "Бервакыт без Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән бергә утыра идек. Аның бәхетле йөзеннән мин аңа вәхи иңгәнен күрдем, аннан соң без выжылдап бал корты очып үткәндәге кебек тавыш ишеттек. Вәхи китергән Җәбраил галәйһиссәлләм киткәч, Аллаһның Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм башта безгә карады, аннан соң Аллаһы тәгаләгә мондый сүзләр белән ялварды: "Йа Аллаһ! Арттыр, киметмә бер дә! Нигъмәтләреңне ирештер безгә, мәхрүм итмә безне. Безнең яклы бул, безгә каршы булма!"**

# МӨЭМИННӘРГӘ ХАС СЫЙФАТЛАР

Без, аның янындагылар, сорадык: "Барысы да тәртиптәме, ий, Аллаһның Рәсүле (саллэллаһу галәйһи вә сәлләм)?" Ул болай дип җавап бирде: "Әле генә Аллаһы тәгалә миңа ун аять иңдерде. Кем ул аятьләр хөкеме буенча гамәл кыла, шуларны Аллаһы тәгалә җәннәткә - Фирдәүс-Галиягә урнаштырыр".

Шул шатлыклы хәбәрне җиткергәннән соң Аллаһның Рәсүле (саллэллаһу галәйһи вә сәлләм) "Мөэминнәр" сүрәсенең беренче аятьләрен укый башлады. Ул аятьләрнең мәгънәсе менә мондый: "Тәхкыйк хак мөэминнәр газаптан котылып мәңгелек сәгадәткә ирештеләр. Алар намазларын хушугъ белән укыйлар, Аллаһтан куркып, кечерәяләр. Янә алар буш сүзләрдән, файдасыз эшләрдән баш тарталар. Вә малларының зәкятен бирерләр. Вә алар гаурәт әгъзаларын күрсәтмәсләр һәм зинадан сакланырлар. Мәгәр үз хатыннарыннан вә хуҗа булган җария хатыннан сакланмаслар, моның өчен алар шелтә ителмәсләр. Берәү үз хатынынан вә җариясеннән башканы эстәсә, ягъни зина кылса, ул кешеләр хәлалдән хәрамга үтүчеләрдер. Янә алар тапшырылган әманәтләргә вә биргән вәгъдәләргә хыянәт итмәсләр. Вә намазларын вакытында укырлар. Ошбу кешеләр хокукый җәннәт варисларыдыр. Алар Фирдәүс җәннәтенә варис булырлар һәм алар анда мәңге калырлар" ("Мөэминнәр", 1-11).

Бу аятьләрнең иң беренчесендә үк мөэминнәрнең газаптан котылып калуы, ягъни, фани бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхет һәм бәрәкәткә ирешәчәкләре турында әйтелә.

Мөэмин - иман китергән кеше. Яхшы. Ә иман үзе ни була?

Иман шул ике нигездән тора:

1. Күңел белән Аңа ышану,

2. Тел белән шәһадәт китерү.

Бәлки шуңа күрә дә Аллаһы тәгалә шушы сүзләрне әйткәндер: "... хак мөэминнәрнең күңеленә Аллаһ иманны ныклап беркетте, вә аларны Үзеннән булган рухи куәт белән куәтләде" ("Мүҗадәлә (Бәхәсләшү)", 22).

Аллаһ тәгалә тәкъдиреннән узу беркемнең дә ихтыярында түгел. Кеше нинди генә югары вазыйфа башкармасын, нинди генә зур көчкә ия булмасын, ул Аллаһы тәгалә тәкъдиреннән уза алмый.

Моңа мисал китереп китүне телисезме? Иң беренче мөселманнарның берсе Билал бине Рабахның (радияллаһу ганһү) иманы моңа мисал булып хезмәт итә ала. Мөшрикләр аны ислам динен кабул иткән өчен Мәккәнең кайнар комына ташлаганнар, күкрәгенә авыр ташлар өйгәннәр, ничек теләсәләр, шулай газаплаганнар, ләкин аның күңелендәге иманын ала алмаганнар. Иң мәрхәмәтсез, иң залим мөшрикләрнең берсе Умаййа бине Хәләф Билалгә: "Ий, Билал! Мөхәммәд Аллаһыннан баш тарт!" - дип әйтә-әйтә аны газаплый торган булган. Күңеле тулы Аллаһка сөю булган Билал газаплаган саен: "Ул бер, бердәнбер ... Аллаһым бер. Ул - Бакый. Ул - ата да түгел, ул да түгел ... Ул - җирнең, күкнең, булганнарның барысының да Раббысы. Ул - Иң Кодрәтлесе, Ул - Иң Шәүкәтлесе. Мин Аңа гына сәҗдә кылдым, маңгаем белән бары тик Аңа сәҗдә кылдым", - дип кычкыра торган булган.

Билал - кол, Умаййа бине Хәләф аның хуҗасы булган. Ул аңа: "Син миңа каршы барасыңмы? Мин синең хуҗаң түгелменни?" - дип кычкырган. Ә Билалнең җаваплары күпкә төгәлрәк булган: "Ий, Умаййа! Сиңа каршы барып, мин Аллаһы тәгаләнең ихтыярына итагать итәм (буйсынам), Син мине күпме телисең, шул кадәр кыйнарга, газапларга мөмкинсең. Син минем, кабергә кергәч кортлар ашый торган тәнемә генә зыян сала аласың. Тик минем күңелемә, минем йөрәгемә, минем аңыма син берничек тә ирешә алмыйсың, аларга берничек тә зыян да сала алмыйсың, алар Аллаһы тәгалә ихтыярында".

Күңелендә шундый нык иманга ия булган Билал Хәбашиның (радияллаһу ганһү) Аллаһ каршындагы дәрәҗәсе нинди соң? Әйдәгез, аның Аллаһ каршындагы дәрәҗәсен Аллаһ Рәсүле саллэллаһу галәйһи вәсәлләмнең Мигъраҗдан кайткач әйткән хәдисе аша карап китик: "Күкләрдә һәм җәннәт бакчаларында мин синең сандал тавышын ишеттем. Билал, син ничек миңа кадәр анда була алдың?" Билал (радияллаһу ганһү) аңа болай дип җавап биргән: "Тәһарәтем бозылгач, мин аны яңарттым. Тәһарәт алгач, Аллаһ ризалыгы өчен ике ракәгать намаз укыдым!"

Мөхтәрәм җәмәгать!

Мөэминнәрнең сыйфатларын бәян иткән аятьләрнең шәрехләре белән танышып китик: "Тәхкыйк хак мөэминнәр газаптан котылып, мәңгелек сәгадәткә ирештеләр. Алар намазларын хушугъ белән (ихлас, чын күңелдән бирелеп) укыйлар" аятенә килгәндә, ул намазны тыныч күңел белән укуны, намаз укыган вакытта итагатьле булуны, кул һәм аяклар белән кирәкмәгән хәрәкәтләр ясамауны аңлата.

Намаз укыган кешенең ничек итеп күңеле тыныч булмаска һәм аның аяк-куллары, тәненең башка урыннары тынгысызланып, кирәкмәгән хәрәкәтләр ясарга мөмкин? Аллаһ Рәсүле саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнең намаз укуның әһәмиятен ничек аңлатуын тыңлап китегез. Ул болай ди: "Аллаһ колы намаз укыган вакытта Аллаһы тәгалә аңа Үз гүзәллеген ирештерер. Әгәр дә Аллаһ колы намаз укыган вакытта уңга-сулга таба борылып карый-карый намаз укыса, Аллаһы тәгалә аңа: "Миннән башыңны борып, читкә карыйсың, әллә анда Миннән дә яхшырак кем дә булса бармы?" - дияр".

Мөхтәрәм Гайшә (радияллаһу ганһә) Аллаһ Пәйгамбәре саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнең намаз укуы турында болай дип сөйли: "Ул безнең белән сөйләшеп, безгә аңлата иде. Без дә аңа ни дә булса сөйли торган идек. Ә намаз вакыты җитсә, ул билгеле бер халәткә кереп китеп, безне күрми дә башлый иде һәм, шулай ук, без дә.

Исламның бөек герое Имам Гали (радияллаһу ганһү) намаз укыган вакытта, аның йөзе акка, сарыга әйләнә торган булган. Йөзенең ни өчен шулай үзгәрүе турында сорагач, ул: "Чөнки мин бу вакытта кешеләргә йөкләнгән, күкләр һәм җирләр башкарырга алынмаган бөек әманәтне башкара башлыйм!" - ди торган булган.

Хөрмәтле мөселман кардәшләр!

Хатам әл-Асам атлы бер тәкъва кешедән: "Намазга баскан вакытта син үзеңне ничек хис итәсең?" - дип сорагач, ул: "Намазга баскан вакытта мин үземне: каршымда - Кәгъбәтулла, артымда - үлем, уң ягымда - җәннәт, сул ягымда - тәмуг, ә мин үзем - сират күперендә торган кебек хис итәм, ә Аллаһы тәгаләнең мине һәрчак күреп торуын беләм. Мин һәр сәҗдә һәм рөкүгъне шундый рухи күтәренкелектә кылам, бар намазны да шундый рухи күтәренкелектә башкарам. Намазны укып бетергәч, Аллаһы тәгалә минем бу намазымны кабул иткәнмеюкмы икәнен мин белмим, шуңа күрә дә аңа борчылам, курку хисләре кичерәм", - дигән.

Аллаһы тәгаләнең: "... алар буш сүзләрдән, файдасыз эшләрдән баш тарталар" сүзләрен шәрехләүгә килгәндә, аларны болай аңларга була: Бу сүзләр безнең тәнебезнең дә, телләребезнең дә чиста, пакъ булырга тиешлеген аңлаталар. Аллаһы тәгаләнең изге хәдистә ни әйткән тыңлап китегез: "Әгәр дә Минем колым теле һәм аяк араларында чиста булуына гарантия бирә икән, Мин аңа җәннәткә гарантия бирәм ..."

Әйе, Аллаһы тәгалә телен ялган һәм теләсә нинди оятсызлыктан тыеп торган кешегә гарантия бирә. Әгәр дә мөэмин үз намусын, үз вөҗданын тиешенчә сакласа, Аллаһ аңа җәннәт гарантиясе бирә. Бу турыда белгәннәр, бу турыда белеп, шулай гамәл кылганнар өчен нинди зур бәхет, нинди зур казаныш бу!

Тел сафлыгы ...

Ә сез беләсезме, кешенең әгъзалары аның теленә көн саен ни турында сөйлиләр? Сез дә бу турыда белмисез, мин дә. Әмма Аллаһы тәгаләнең Рәсүле, хакыйкать нуры Бөек Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләм кешенең әгъзалары аның теленә көн саен ни турында сөйләүләрен безгә әйтеп калдырган: "Ий тел! Безнең өчен Аллаһ каршында курык! Чөнки без синең арттан барабыз. Әгәр дә син саф икәнсең, без дә саф, әгәр син гөнаһлы икәнсең, без дә гөнаһлы".

Укба бине Әмир (радияллаһу ганһү) Аллаһ Рәсүле саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнән бервакыт сораган: "Ий Аллаһның Рәсүле, котылып калуның юлы кайда?" Аллаһның Рәсүле саллэллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: "Телең ни әйткәнен игътибарда тот, өең анда керүчеләр өчен иркен булсын, ә хата һәм гөнаһлар җибәргән вакытта тәүбә итеп ела!" - дип җавап биргән.

Хөрмәтле дин кардәшләрем!

Әйдәгез, бу аятьләргә шәрехләр бирүне дәвам итик. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Вә малларының зәкятен бирерләр". Бу аятьтә зәкят түләүнең мөһимлеге аңлатыла. Ягъни, бу аять чын мөэмин сыйфатларының берсе - зәкят түләү икәнлеге турында сөйли. Нинди дә булса мөлкәттән зәкят түләнсә, ул төрле пычраклардан пакьләнгән була. Ә бу вакытта иң мөһиме шунда - түләнгән зәкят өчен Аллаһы тәгалә аны түләгән кешегә тагы да күбрәк нигъмәт ирештерә.

Дөньяларның икесенең дә нуры Бөек Мөхәммәд Пәйгамбәр саллэллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы тәгаләдән безгә шундый сүзләр җиткерә: "Син үзеңнекеннән сарыф ит, ә Мин синең өчен сарыф итәрмен". Ягъни, үз мөлкәтеңнән Минем ризалыгым өчен сарыф ит, ә Мин син канәгать булсын өчен сарыф итәрмен.

Без шуны төгәл әйтә алабыз: "Әгәр дә мөселманнар үз зәкятләрен тиешенчә түләп барсалар, урамнарда хәер сорашкан, кылган җинаятьләре өчен төрмәләрдә утырган яки ялкауланып үз өйләрендә яткан кешеләрне без күпкә азрак күрер идек, яки алар гомумән булмаслар иде. Әгәр дә нефтькә бай илләр үз финанс бурычларын тиешенчә үтәп барсалар, без ислам дөньясында ачка интеккән бер генә кешене дә очрата алмас идек. Ул илләрдә хәер сорашкан кешеләр дә булмаслар иде".

Ә сез нефтьтән килгән табышка зәкят өлеше күпме булуын беләсезме? Ул - табылган нефтьнең биштән бер өлеше кадәр. Әйе, нефть шәехләре мөлкәтләренең биштән бере зәкят итеп түләнергә тиеш. Дөньяда тәүлегенә ун миллион баррель нефть тапкан илләр дә бар, шул исәптән мөселман илләре дә. Аларның нефть табудан түләргә тиешле зәкятләре тәүлегенә ике миллион баррель нефть хакы кадәр тәшкил итә. Әгәр дә ярлы мөселманнар өчен көн саен ике миллион баррель нефть хакы кадәр зәкят түләгән нефтькә бай бер генә ил булса да, Аллаһ белән ант итәм, мөселманнар арасында бер генә ярлы кеше дә калмас иде. Ә хәзер инде уйлап карагыз, нефтькә бай илләрнең барысы да зәкятләрен тиешенчә түли башласалар, ул вакытта ни булыр иде? Ул вакытта бар дөньяда бер генә ярлы кеше дә калмас иде.

Аллаһы тәгалә бай кешеләргә нәрсә ди? Фәкыйрь ке-

шеләргә? Әйдәгез, менә бу хәдисне игътибар белән тыңлыйк һәм аның мәгънәсен тулысынча аңларга тырышыйк: "Бай кешеләр - минем ышанычлы кешеләрем. Ә фәкыйрь кешеләр - минем асрамадагы кешеләр. Әгәр дә минем ышанычлы кешеләрем минем асрамадагы кешеләремә карата саранлык күрсәтсәләр, алар минем игътибарымнан мәхрүм ителерләр һәм мин алардан читләшермен ..."

Мөхтәрәм җәмәгать!

Гомәр бине Габделгазиз хакимлек иткән чорда, тиешле бар зәкятләрне җыеп алып, аларны мохтаҗларга таратырга дигән карар чыгарыла. Ләкин дәүләттә зәкят аша ярдәм алырга мохтаҗ кеше табылмый. Ул вакытларда мәмләкәтнең чикләре: көнчыгышта - Кытайга, көнбатышта - Парижга, төньякта - Себергә, көньякта - Һинд океанына кадәр җиткән була. Мәмләкәт күп кенә кечерәк дәүләтләрне үз составына алган була һәм анда бик күп сандагы халык яши. Шулкадәр дә зур мәмләкәт булуына да карамастан, бар мәмләкәттә зәкят аша ярдәм алуга мохтаҗ кеше табылмый, ислам кануннары буенча тормыш алып барган бу мәмләкәттә халык иркен, мул тормышта яши торган була. Хатын-кызлар андый дәүләттә дөньяга фәкыйрь балалар тудырудан туктыйлар. Ни өчен? Чөнки, Гомәр бине Габделгазиз элеккеге хакимнәр җибәргән ялгышларны төзәтүгә ирешә. Ул үз хакимлеге чорында зур гаделлек белән хакимлек итә. Бу яктан ул әнисе ягыннан үзенең бабасы Гомәр бине әл-Хаттаб (радияллаһу ганһү) кебек була ...

Бөек хәлифә Гомәр бине Габделгазиз үзенең җирле әмирләрнең берсен шелтәләп яткан вакытта Мисыр әмире Яхья бине Садтан: "Сад, син монда килгән вакытта Мисырны нинди халәттә калдырдың?" - дип сораган. Мисыр әмире Яхья бине Сад аңа: "Бик яхшы гына хәлдә калды Мисыр, ий Мөэминнәрнең Хакиме; байлар үз бурычларын башкаралар, мохтаҗларның ихтыяҗлары канәгатьләндерелгән, кыерсытучылар җәзага тартылган, кыерсытылганнарга ярдәм күрсәтелгән", - дип хисап биргән.

Димәк, бу вакытта гаделлек өскә чыккан, ә Аллаһ хөкемнәре төгәл башкарылганнар, кешеләр, Аллаһка өмет баглап, үз тормышларын Аның ихтыярына тапшырганнар ...

Ә Мисыр исә, үзенең юньсез традицион гадәтләре белән күптән үк билгеле булган. Мисырда элек ел саен бер кызны бизәндергәннәр дә, корбан итеп Нил елгасына ташлаганнар. Аннан соң алар: "Бу кыз - Нилның кәләше", дигәннәр. Мисыр кешеләре, әгәр дә Нилга ел саен корбан китермәсәң, ул тулы сулы булмаячак, кибәчәк һәм файдалану өчен яраксызга әйләнәчәк, дип исәпләгәннәр.

Мисырда хакимлек мөселманнар кулына күчкәч, Амр бине Ас (радияллаһу ганһү) бу турыда мөэминнәрнең хакиме Гомәр бине әл-Хаттабка (радияллаһу ганһү) сөйләгән. Гомәр (радияллаһу ганһү) ни эшләгән соң? Ул шунда ук кулына каләм алган да мондый хат язган: "Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһ исеме белән! Гомәр бине Хаттабтан Мисырның Нилына: "Ий Нил! Әгәр дә син үз ихтыярыңда гына агып ятсаң, безнең синдә хаҗәтебез юк. Ә әгәр дә син Аллаһы тәгалә Ихтыяры буенча агасың икән, Аның хөкеме буенча агуыңны алга таба да дәвам ит".

Шул ук вакытта Гомәр (радияллаһу ганһү) әмир Амр бине Аска (радияллаһу ганһү) да хат белән мөрәҗәгать иткән: "Ий Амр, син Нилга корбан итеп кызны ташлама, ә мин җибәргән менә шушы хатны ташла. Чөнки андый корбан китерү җаһилият традициясе булып тора, ә җаһилият традицияләре - ялган традицияләр".



Амр бине Ас (радияллаһу ганһү) Гомәр бине әл-Хаттабның (радияллаһу ганһү) әлеге әмерен үтәгән һәм Нилның суы шуннан соң ике тапкыр арткан. Бу - Аллаһы тәгаләгә ышануның, Аңа сыгынуның, Аңа өмет баглауның, Аның хөкемнәренә тәкълид итүнең, Аңа рәхмәтле булуның, Аны сөюнең, Аның тәкъдиреннән канәгать булуның нәтиҗәсе, шуның әҗере.

Хәзер инде Гомәр бине Габделгазизгә кайтыйк. Ул: "Зәкят мөлкәтен бурычлары булган кешеләрнең бурычларын каплау өчен тотарга", - дип карар чыгарган. Бу акчалар белән илдәге бар бурычлар да капланган, бурычлы кешеләр башка калмаган, илдә бәрәкәт арткан, ул тагын да байрак була башлаган. Дәүләтнең бюджеты тулган, илдә хәер сорашкан бер кеше дә калмаган. Гомәр бине Габделгазиз алга таба яңа фәрман чыгарган: "Коллары булган кеше, дәүләт бюджетыннан акча алып, колларын азат итсен". Коллары булган бар кеше дә ул кушканча эшләгән. Ләкин моның белән генә зәкят акчалары бетмәгән. Аннан соң ул өченче әмерен чыгарган: "Өйләнү өчен финанс мөмкинлекләре булмаган кешеләр дәүләт акчасына өйләнсеннәр". Өйләнә алмый йөргән бар буйдаклар да өйләнгәннәр. Ләкин моннан казна бер дә бушамаган. Әйе, шулай итеп, бурычлар да капланган, коллар да азат ителгән. Буйдак кешеләр калмаган.

Аллаһның Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең бу турыда ни әйтүен тыңлап китегез: "Сезнең арагызда иң начарлары - өйләнмәгән кешеләр. Вафат булганнар арасында иң юньсезләре - өйләнмичә вафат булганнары". Бәлки шуңа Аллаһы тәгалә, вөҗдан һәм намусыңны сакларга кушып, болай дип әйткәндер дә: "Вә алар гаурәт әгъзаларын күрсәтмәсләр һәм зинадан сакланырлар. Мәгәр үз хатыннарыннан вә хуҗа булган җария хатыннан сакланмаслар, моның өчен алар шелтә ителмәсләр. Берәү үз хатыныннан вә җариясеннән башканы эстәсә, ягъни зина кылса, ул кешеләр хәләлдән хәрамга үтүчеләрдер".

Мөхтәрәм җәмәгать!

Монда "сакланырлар" сүзендә бер үзенчәлек бар. Ул үзенчәлеккә сез дә игътибар иткәнсездер дип уйлыйм. Бу аятьтә намусны саклауның зарурлыгы - икенче бер аятьтә даими намаз укуны саклауның зарурлыгы күрсәтелгән кебек күрсәтелгән ... Димәк, вөҗдан һәм намусны саклауның мөһимлеге һәм Аллаһ каршындагы дәрәҗәсе - намаз укуны саклауның мөһимлеге һәм Аллаһ каршындагы дәрәҗәсеннән ким түгел.

Бу аятьтә үзләренең вөҗдан һәм намусларын саклаучылар, зина кылмаучылар мактала. Ә бу исә чын мөэминнәрнең төп сыйфатларының берсе нәкъ менә шул булуын күрсәтә. Бәлки шуңа күрә дә Аллаһның Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм менә бу сүзләрне әйткәндер дә: "Ий яшьләр! Өйләнер өчен мөмкинлекләре булган кешеләр өйләнсеннәр. Чөнки, өйләнү күзләрне гөнаһтан саклый, ә җенес әгъзаларын - зинадан. Ә кемнең өйләнү өчен мөмкинлеге юк икән, ул кеше ураза тотсын, чөнки ураза җенси дәртне сүрелдерә".

"Берәү үз хатыныннан вә җариясеннән башканы эстәсә, ягъни зина кылса, ул кешеләр хәләлдән хәрамга үтүчеләрдер" сүзләре - никахтан тыш мөнәсәбәтләрнең һәм гомосексуализмның исламда тыелган булуы турында сөйли. Чөнки бу гөнаһлар рөхсәт ителгәннәрнең чикләрен үтеп киткән кешеләрнең гөнаһлары булып исәпләнә. Аллаһның Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм өйләнергә теләп тә, моның өчен мөмкинлеге булмаган кешеләргә, мондый хәлдән чыгуның юлын күрсәткән. Алар я өйләнергә, яки, үз-үзләрен тотып тору һәм зина кылудан саклану өчен, ураза тотарга, яисә күбрәк Коръән һәм намаз укырга, зикер әйтергә тиешләр.

Бу аятьтәге "алар тапшырылган әманәтләргә вә биргән вәгъдәләргә хыянәт итмәсләр" сүзләре ышанып тапшырылган әманәтләрне һәм килешүләрне үтәү зарурлыгын аңлата. Әманәтләрнең - ышанып тапшырылганнарның - күп төрләрен мисал итеп китерергә була, мәсәлән, намаз да әманәт булып тора, ятимнәрнең саклап тору өчен ышанып тапшырылган мөлкәте дә - әманәт. Әгәр дә кеше боларның барысын да үти икән, бу аның Аллаһ хокукларын саклавын, Аның каршында биргән вәгъдәләрен үтәвен аңлата.

Сүрәнең башында чын мөэминнәрнең намазны хушугъ белән укулары турында әйтелә. Ягъни, чын мөэмин намазны ихлас, чын күңелдән, дулкынланып укырга, бу вакытта аның кул-аяклары кирәкмәгән хәрәкәтләр башкармаска тиеш ...

Намаз уку темасын дәвам итеп, шуны әйтеп китик: намаз вакытында укырга тиеш. Әгәр дә син намаз уку вакытын үткәреп җибәргәнсең икән, бу - синең гөнаһ кылуыңны аңлата.

Хөрмәтле һәм кадерле мөселманнар!

Әгәр дә чираттагы намазын калдырган кеше гөнаһлы кеше булып санала икән, мөэминнәрнең атналык вазыйфасы - җомга намазын калдырган кешенең Аллаһ каршында хәле нинди? Ә рамазаннан рамазанга кадәр, унбер ай буе намаз укымаган мөселманнарның Аллаһ каршындагы хәле нинди? Ә гомумән намаз укымаганнарның? Ә бит аларның гомерләрендә бары тик бер генә намаз - вафат булгач, аның рухы өчен башкаларның җеназа намазы укулары гына бар.

Мөбарәк бу сүрәнең аятьләрендә болай дип әйтелә: "Алар намазларын хушугъ белән укыйлар... Вә намазларын вакытында укырлар".

"Намаз ул - минем күз нурларым", - дигән Аллаһның Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм. "Намазын калдырган кеше Фиргавен, Хаман, Карун һәм Убаййа бине Хәләф белән бер үк урында булыр", - дигән. "Намазларын вакытында башкарганнарны, моның өчен зур әҗер көтә. Ә аның әҗере ни соң? Алар - Фәрдәвес җәннәте вәгъдә ителгән кешеләр. Фирдәвес җәннәте - җәннәтнең иң дәрәҗәле, иң югары урыны. Алар мәңге шунда булачаклар. Кешеләр җәннәттә урнашкач, Аллаһы тәгалә әйтер: "Сез монда беркайчан да авырмассыз, һәрвакыт сау-сәламәт булырсыз. Сез беркайчан да үлмәячәксез, мәңге яшәячәксез. Сез беркайчан да картаймаячаксыз, мәңгегә яшь булып калачаксыз. Сезгә монда тыныч тормыш булыр, сез беркайчан да өметегезне өзмәячәксез. Җәннәт әһелләре, әйтегез әле, сез боларның барысы белән дә канәгатьме?" Җәннәт әһелләре: "Ий, Раббыбыз! Без ничек канәгать булмыйк, Син безгә башка беркемгә дә ирештермәгән рәхмәтеңне ирештердең бит", - диярләр. Шуннан соң Аллаһы тәгалә әйтер: "Мин сезгә моннан да яхшыракны, моннан да гүзәлрәкне ирештерәм әле". Җәннәт әһелләре сорарлар: "Моннан да яхшырак, моннан да гүзәлрәк тагын ни булырга мөмкин?" Шуннан соң Аллаһы тәгалә Аны каплап торган "пәрдәне" ачып җибәрер һәм аларга Үзенең иң Гүзәл һәм Бөек Йөзен күрсәтер, җәннәт әһелләре Аның ул Йөзен күрә алу бәхетенә ирешерләр. Аны сүз белән сөйләп, бәян итеп бетерү мөмкин түгел. Аллаһы тәгалә әйтер: "Кыямәт көнендә кайбер йөзләр шатланып агаручыдыр. Ул йөз Раббысына караучыдыр" ("Кыямәт", 22-23).

Йа Раббыбыз!

Намазларын хушугъ белән укучылардан әйлә безне! Буш сүзләрдән, файдасыз эшләрдән баш тартучылардан, зәкятләрен түләүчеләрдән, вөҗдан һәм намусларын саклаучылардан, әманәтләренә һәм вәгъдәләренә хыянәт итмәүчеләрдән, намазларын беркайчан да кадырмаучылардан безне әйлә! Безне андагы хур кызлары белән бергә Фирдәвес җәннәте әһелләреннән, үзебезнең иң зур максатыбыз - Синең Мөбарәк Йөзеңне күрүчеләрдән әйлә!

Амин!

*Татарстан*
*Республикасы мөфтие*
*Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН*

# ИСЛАМ. ТӘКЪЛИФ

**Ислам - Бер Аллаһыга Аның кануннарына нигезләнеп буйсыну. Аллаһы тәгаләнең Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иңдергән һәм мөселманнар буйсынып яши торган кануннары бөтенесен дә үз эченә ала.**

Исламның төп биш баганасы бар:

1. Шәһадәт - исламга килү таныклыгы.
2. Көндәлек биш вакыт намаз уку.
3. Ел саен рамазан аенда ураза тоту.
4. Ел саен зәкят түләү (мал-мөлкәтле кешеләр өчен).
5. Гомергә бер хаҗ кылу (мөмкинлекләре булган кешеләр өчен).

Беренче чиратта, исламны кабул итү өчен кеше шәһадәт сүзләрен әйтергә тиеш, аннан соң намаз укырга өйрәнә. Рамазан ае килеп җиткәч, ул ураза тота башлый. Хаҗга бару вакыты җиткәч, матди һәм физик мөмкинлекләре булса, хаҗга барырга тиеш. Бер һиҗри ел узуга хәлле мөселман зәкят түләргә, ягъни үз милкеннән артканның бер өлешен ярлы мөселманнар файдасына бирергә тиеш.

Исламның төп баганаларын үтәү һәр мөкалләф өчен мәҗбүри булып тора. Мөкалләф - балигъ булган аңлы кеше. Кеше мөкалләф булып ирешүгә шәригатьнең барлык кануннарын үтәргә тиеш була. Тәкълиф (исламны тоту вазифасы) акылдан язганнарга һәм балигъ булмаган балаларга кагылмый. Кеше исламның төп кагыйдәләрен аңлы рәвештә үтәми икән, ул гөнаһлы була һәм үзенә зур зыян китерә.

*"Ислам турында сөйләшик" энциклопедиясеннән*

## ТЕШ СЫЗЛАГАНДА УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

Сахабәләрдән Абдуллаһ бине Рәвәхә (р.г.) беркөнне Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә теше сызлаудан изалануы хакында сөйләгән иде. Рәсүлуллаһ бәрәкәтле кулын Хәзрәти Абдуллаһның авырткан яңагына куеп, болай диде: **"Аллаһүммәәзһиб гәнһү сүүә мә йәҗидү үә фәхшәһү би дагьүәтии нәбийикәль-мәкииниль-мүбәәраки гиңдәк". Мәгънәсе: "Аллаһым! Синең каршыңда мөбарәк һәм мөхтәрәм булган пәйгамбәреңнең догасы белән бу тешнең авыруын ал"** ***(Мевахибуль-Ләдүнния: 75).***

# Идеаль хатын нинди була?

**Коръәни-Кәрим буенча, гаилә тормышы - иң яхшы тормыш, яшәүнең башка формалары кимчелекле дип исәпләнә. Коръәни-Кәримдә кешеләрнең иң баштан ук пар итеп - ир-ат һәм хатын-кыз итеп яралтылганлыгы, кешенең үз парыннан башка яши алмавы аңлатыла. Ир-ат һәм хатын-кыз бер-берсен тулыландырыр өчен яралтылганнар, шуңа күрә, камиллеккә ирешер өчен алар бер-берсенә мохтаҗ.**



"Ән-Ниса" һәм "Әл- Бәкара" сүрәләрендә мөэмин һәм яхшы ир белән хатын "игелек" сүзе белән аталган. Игелеккә һәр кеше омтыла. Мөэминә хатыннарның игелек дип аталуы, аларның яхшы һәм кадерле булуларын гына түгел, ирләрен яхшылыкка һәм игелеккә өндәүләрен һәм аларның үсүләренә сәбәпче булуларын да күрсәтә. Шул ук вакытта бу аятьләр хатын сайлаганда беренче чиратта нәрсәгә игътибар итәргә кирәк икәнен дә аңлата. Башкача әйткәндә, бу дөнья тормышының бик тиз үтүен белүче һәм киләчәк тормыш турында уйлаучы кешеләр үзләрен игелеккә өндәүче, рухи үсешләренә булышлык күрсәтә алырлык хатын эзләргә тиеш. Шул рәвешле алар ике дөньяда да тынычлыкка ирешә алырлар.

Аллаһы тәгалә Коръәни-Кәримдә болай дигән: "Әгәр рәсүл галәйһиссәлләм сезне талак кылса, Раббысының аңа сезне яхшырак хатыннарга алыштырмаклыгы өметледер, алар: чын мөслимәләр вә Аллаһыга, Аның һәр сүзенә ышанучы хак мөэминәләр, Аллаһыга вә рәсүлгә чын итагать итүчеләр, вә гөнаһтан тәүбә итүчеләр, вә Аллаһыга гына гыйбадәт кылучылар, вә ураза тотучылар, вә рәсүлгә итагать өчен һиҗрәт итүчеләр, шул сыйфатта булган хатыннар ирдә булган тол хатыннардыр һәм ирдә булмаган кызлардыр. Аллаһы теләсә сезне әнә шундый хатыннарга алыштырыр, димәк" ("Тәхрим (Тыю)", 5).

Бу аятьтә камил хатын сыйфатлары санала: иман, матур әхлак, тышкы матурлык һәм гыйффәтлек. Ләкин бу һәм башка мөэмин хатын-кызларның сыйфатлары саналган аятьләрдә төп шарт булып иман тора. Димәк, үзенә хатын сайлаганда ир-ат беренче чиратта аның иманына игътибар итәргә тиеш.

Икенче мөһим сыйфат - матурлык, ләкин иман белән чагыштырганда матурлык икенче урында. Әгәр дә кеше матурлык һәм иман арасында сайларга тиеш икән, әлбәттә, ул матурлыгы түгел, ә иманы булган кешене сайларга тиеш.

Әгәр дә без Коръәни-Кәримдә язылганнарны исәпкә алсак, хатыныбызның тышкы кыяфәтенә генә түгел, иманына да игътибар итсәк, Коръәни-Кәримдә биргән вәгъдәсе буенча, Аллаһы тәгалә йөрәкләребезне мәхәббәт белән тутырыр, һәм бу кеше безнең өчен иң матур булыр. Әгәр дә нәфесебезгә хуҗа була алмыйча, матур, ләкин иманы булмаган хатын сайласак, тиз арада Аллаһы тәгалә ярдәменнән мәхрүм калачакбыз, имансыз һәм тиздән матурлыгын югалтачак кеше белән гомер кичерәчәкбез.

Икенче мөһим һәм гаилә тормышы өчен зур мәгънәсе булган сыйфат - гыйффәтлек. Күпчелек хәдисләрдә гыйффәтле кызларга өйләнергә кушыла. Гыйффәтлек тышкы матурлыкка караганда күпкә мөһимрәк, ләкин иман белән бер дәрәҗәдә мөһим түгел.

# ИСЕМ КУШУ

**Имам яңа туган баланың исемен аның әти-әнисе белән алдан ук килештерсә яхшы. Исем ислам дине традицияләренә туры килергә тиеш. Әгәр дә баланың әти-әнисе ислам принципларына каршы килә торган исем сайласа, имам аны төзәтергә яки башка исем сайларга ярдәм итәргә бурычлы. Ата-ана һаман да элек сайлаган исемне тәкърарласа, имам исем кушудан баш тартырга да хокуклы. Исем кушу алдыннан имам вәгазь укый, мәҗлестә катнашучыларга - яңа туган баланың әти-әнисенә - Хак тәгаләнең никадәрле шәфкатьле булуын аңлата, баланы дөрес тәрбияләүнең әһәмияте, аның ата-анага карата хокуклары турында сөйли.**

### ИСЕМ КУШУ ТҮБӘНДӘГЕ РӘВЕШТӘ ҮТӘ

Баланы, аякларын кыйблага юнәлтеп, өстәлгә яисә караватка салалар. Аннары имам, аның баш очына басып, кыйблага карап азан әйтә, азан догасын укый һәм баланың уң колагына аның һәм атасының исемен әйтә. Мәсәлән, "Габдрахман улы Мәхмүд", яисә "Фатыйх кызы Гайшә". Алга таба ул камәт төшерә. Камәттән соң баланың сул колагына иелә һәм аның исемен әйтә. Аннан соң имам түбәндәгечә дога кыла: "Әллаһуммә әнбитһү фил исләми нәбәтән хәсәнән вүҗгалһү мәсгудән фиддунья үәл әәхирә". Мәгънәсе: "Йә Раббым, ошбу баланы ислам динендә тәрбияләп үстер һәм аны ике дөньяда да бәхетле ит".

Шулай ук дога татар телендә яисә баланың әти-әнисенең туган телләрендә дә укылса - бик күркәм. Мәсәлән, "Йә Раббым Аллаһы! Бу бала ислам динен куәтләүче, ата-анасына игелекле, миһербанлы-шәфкатьле, тәүфикълы бала булса иде. Ата-аналарына тигезлек, саулык-сәламәтлек белән аны үстерергә насыйп итсәң иде".

*"Гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында нигезләмә"дән*



# КОРЪӘН УКЫП, КҮЗЕ АЧЫЛДЫ

**Мәчеттә иң хөрмәтле вә ихтирам ителә торган кешеләрнең берсе ул Сәвия ханым. Җомга көннәрендә ашыкмыйча гына Казандагы бер гыйбадәтханәнең ишеген ачып кергәч, андагы барча мөселманнар белән тыйнак кына: "Әссәләәмү галәйкүм",- дип исәнләшер. Аннары икенче катка күтәрелер һәм андагы мәчет әһелләренә сәлам биреп узар. Куанып яши ул иман йортына көннәнкөн күбрәк инсан килүенә. Аеруча җомга көннәрендә намаз уку залы кеше белән шыгрым тулы була.**

Сәвия ханымның күңеле үзенең тормыш хәлләрен җәелеп сөйләүне өнәми. Моны тыйнаксызлык билгесе дип саныйдыр, күрәсең. Шулай да беркөнне миңа аның хәятендәге кыйссаларны тыңлау һәм бик авырлык белән генә бу хакта язырга рөхсәт алу насыйп булды.

...Әти-әнисе бик иртә гүр иясенә әйләнә Сәвиянең. Апалары Сабира 1948 елда 12 яшьлек Сәвия белән Сәкинәне Үзбәкстан якларына алып китә. "Минем янда ач-ялангач булмассыз", - дип аңлата ул үзенең бу карарын. Алар Ташкенттан шактый ераклыкта урнашкан бер калада үзбәкләр белән аралашып үсәләр һәм мәктәптә укыйлар. Сәвиягә бик иртә тормыш арбасына җигелергә туры килә. Ул 1955 елда укытучы сыйфатында мәктәп бусагасын атлап керә һәм 40 ел буена берөзлексез балалар укыта. Эшен яратып, тәм табып башкара. Рәсим исемле татар кешесенә кияүгә чыгып, 5 бала табып үстерәләр. Тик рәхәт булса да торган җир, сагындыра туган ил дигәндәй, җирсү хисләре кичерә. Татарстан гел дә күңелен кымырҗытып, үзенә тартып тора.

Тәкъдиреңдә ни язылган булса, шуннан уза алмыйдыр инде адәм баласы. Менә бер-бер артлы кайгы-хәсрәт аларның ишеген шакый. "Көтмәгәндә-уйламаганда 2 улым гүр иясе булды. Капкадан чыгуга, берсен машина бәрдереп китте. Ә икенчесе - пәһлеван гәүдәле Айрат улыбыз бандитлар кулыннан һәлак булды. Ул, армиядә хезмәт итеп кайткач, төзелеш институтына кереп, аны уңышлы гына тәмамлады. Бер оешмада инженер булып эшләргә кереште. Намазларын да укый башлаган иде. Матур киенеп йөрергә ярата. Машина да алып бирдек үзенә. Бәла агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри, дип бик белеп әйткән борынгылар... Улларыбыз җан тәслим кылгач, йөрәгемә кара кан саугандай булды. Үксеп-үксеп еладым. Күз яшьләрем кибеп бетте. Ул чактагы хәлебезне үз башына шундый кайгы-хәсрәт төшкәннәр генә аңласа аңлар. Берәүгә дә андый язмышны теләмим..."- ди Сәвия ханым.

Бу фаҗигане ире Рәсим дә бик авыр кичергән. Ул башларына төшкән бәла-казаларны кемгә дә булса сөйләп, күңелен бушатмаган, эчтән янган, эчтән кайгырган. Татарстанга күченеп кайтуларының бер сәбәбе дә шул: авыр кичерешләрдән беразга гына булса да онытылып торырбыз, дип өметләнгәннәр. Тик балаларның ачы язмышы онытыла торган кайгы түгел шул...Тиздән аның ире авырыга сабыша һәм моннан 4 ел элек мәңгегә күзләрен йома.

Күзләр димәктән, әллә инде күп дәфтәрләр тикшергәнлектән, әллә күз яшьләре кибеп беткәнлектән, Сәвия ханымның күзләре начарая. Ә беркөнне төпчек улы белән "Тасма" янындагы кибеткә кергәч, ул бер күзенең бөтенләй диярлек күрмәвен шәйләп ала. Кичекмәстән нәрсә булса да эшләргә кирәк була. Намазны балачактан ук өйрәнгән анысы. Фарыз булган мөһим гыйбадәтләрен калдырмый ул. Шулай да ниндидер гамәлне кылып бетермәгәндәй тоела аңа. Уйлана торгач, тәки эзләп таба: баксаң, дөнья артыннан куып, Коръәнне ныгытып укый алмаган икән ул! Тик менә күзенең начар күрә башлавы гына бу изге эшкә комачаулык итмәсме? Шөкер, монысының да җае табыла. Улы Илнур аңа эре гарәп хәрефләре белән басылган зур Коръән алып кайтып бирә.

Шуннан нәрсә булган дисезме? Изге Китапны кулларына алып, "Фатиха" сүрәсен укый башлауга ук теге күздәге элпәнең эреп югала баруын сизә ул. Шуннан соң Коръән укуны көн дә үти торган күркәм гадәткә әйләндерә. Бераз соңрак чын мәгънәсендәге могҗиза барлыкка килә: сукыраеп барган теге күз тәмам ачылып, элеккеге хәленә кайта!

... Ул вакыйгалардан соң инде шактый карлар яуган, сулар аккан. Бүгенге көндә Сәвия ханымның күзләре, Аллага шөкер, Коръәннең вак хәрефләр белән язылганын да укый ала. Менә шуңа күрә дә куанычы эченә сыймый аның. Инде ул ике тапкыр Коръән хәтем кылды, ягъни Изге Китапны тулысынча укып чыкты. Хаҗга барып кайту бәхетенә дә ирешә. "Коръән укуның күзгә генә түгел, авырткан аякларыма да файдасы тиде. Тик аны бәдәнемә шифа булсын, дип кенә түгел, ә Аллаһының ризалыгын алу максаты белән укырга кирәк. Сезгә киңәшем шул: аз гына буш вакытыгыз чыктымы, аны әрәмгә үткәрмәгез, таһарәтләнеп, Раббыбыздан иңгән Изге Китапны кулыгызга алыгыз. Аллага шөкер, минем балаларым үзләре белеп намазга бастылар, барлык туганнарым, шул исәптән оныкларым да намазлы", - дип сөенә бүген Сәвия ханым Борһанова.

*Хатыйп ГӘРӘЙ*

# НАМАЗДАН ЯЛЫГУ ХИСЕННӘН НИЧЕК КОТЫЛЫРГА

**Безнең гыйбадәтләребездә, кызганыч ки, күптөрле киртәләр очрый. Бу киртәләрне күрә белү һәм алардан җиңел үтә алу тулысынча Аллаһы тәгаләнең ярдәме һәм рәхим-шәфкатенә бәйле. Иң беренче чиратта нәкъ менә шуны аңлый белергә һәм кабул итәргә кирәк. Мисал өчен, Аллаһы ризалыгы һәм аның рәхим-шәфкатен алырга омтылучылар гына намазда хушугъ хисенә (намазны бирелеп укуга) ирешә ала.**

Безнең намаз укуыбыз бик күркәм гамәл. Ләкин намазда хушугъ хисе булмаса, күңелләребез тынгысыз, борчулы булып кала, шайтан безнең калебебезне тынычлыкта калдырмый. Бу - төп бәлабез. Шайтан бар көченә безне намаздан канәгатьлек алудан мәхрүм итәргә тырыша. Ә намаз укудан тулы канәгатьлек алу өчен аны хушугъ белән башкаруның мөһимлеген аңлау - үзе зур бәхет.

Гәрчә без намаз укудан тулы канәгатьлек алып бетермәсәк тә, безнең аны беркайчан да калдырмаячагыбызны шайтан һәм нәфесебез белеп торырга тиеш. Чөнки намаз ул - Аллаһы тәгаләнең әмере.

Арыганлык һәм ялыгу хисеннән котылу өчен түбәндәгеләр бик мөһим:

1. Безнең нәфесебез бар һәм ул намаз укуыбызга каршы бара. Гомер тиз уза һәм гыйбадәтләрдән башка яшәүнең мәгънәсе юк, шуңа күрә дә нәфесебезгә беренче җавап булачак, без тәүлекнең егерме дүрт сәгатенең бер сәгатен булса да мәңгелек тормыш өчен сарыф итәргә тиешбез. Ә моңа исә намаз уку һәм гамәл-гыйбадәтләрнең башка төрләрен башкару юлы белән генә ирешергә мөмкин.



2. Без көн саен физик яктан яшәешебез өчен зарур булган икмәк, су һәм һаваны кулланудан ялыкмыйбыз. Шулай булгач, намазның да тормышыбыз өчен зарур булуын аңларга тырышырга тиешбез, намаз ул - безнең җаныбызга вә күңелебезгә, мәңгелек тормышыбызга кирәк, ул безнең рухи тормышыбыз чыганагы.

3. Нәфесебезгә хас булган сабырсызлыклардан котылу - тагын бер сабак булып тора. Вакытыбызның бер өлешен намаз укуга сарыф итеп, без нәфесебезне сабырлык күрсәтергә мәҗбүр итәбез, аны тәрбиялибез.

4. Намаз ул - безнең күңелебез өчен рухи азык, каберебездә - нур. Кыямәт көнендә, сират күпере аша үткәндә аның нур булачагын без һәрчак истә тотарга тиешбез. Моны истән чыгармаган хәлдә шайтанның котыртуларына һәм нәфесебез галәмәтләренә чик куя алачакбыз.

Югарыда әйтеп үтелгәнчә намаздан канәгатьлек хисе алу өчен без гыйбадәт кылуларыбызда ныклык күрсәтүне дәвам итәргә тиешбез, башка юл юк.

# СОРАУ – ҖАВАП

**- Намазда ни өчен имамнан калмаска кирәк?**

- Имам, мөселманнар арасында хөрмәт һәм бердәмлек символы буларак, җәмәгать белән башкарыла торган намазларны алып баручы итеп билгеләнә, аңа оеп намаз уку ваҗиб (мәҗбүри үтәлергә тиешле) гамәлләрдән санала.

Әз-Зөһри Әнәс бин Мәликтән (радияллаһу ганһү) риваять иткәнчә, Аллаһының рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: "Имам, намаз вакытында башкалар аның артыннан иярсеннәр өчен, алга чыгып баса. Әгәр ул тәкбир әйтсә, сез дә тәкбир әйтегез; әгәр ул сәҗдә кылса, сез дә сәҗдә кылыгыз; әгәр ул сәҗдәдән күтәрелсә, сез дә аның артыннан иярегез. Ул: "СәмигАллаһү лимән хәмидәһ", - дип әйтсә, сез: "Раббәнә үә ләкәл-хәмде", - дип әйтегез" (Мөслим. Китабусаләт, баб: итимәтел-мәгъмум бил иман).

Имам артыннан иярмәү мәкруһ гамәл булып тора, кайбер очракларда ул намазыгызны бозарга да мөмкин.

Әбү Һурайрадан (Аллаһы аңардан разый булса иде) риваять итүләренчә, Аллаһының рәсүле (аңа Аллаһының рәхмәте вә сәламе ирешсә иде) болай дигән: "Сезнең кайсыгыз да булса берәрегез сәҗдәдән башыгызны имамнан алда күтәрсә, Аллаһы аның башын ишәк башына әйләндерер яки аны ишәк кыяфәтенә кертер дигән курку сезне биләп алмыймы?" (Әбү Дауд. Китабу-саләт, баб: әт-тәшдди фи ман ярфагу каблел-имам).

Имам Әгъзам Әбү Хәнифә мәзһәбе буенча әгәр дә имам белән бергә намаз укыган кеше сәҗдә яки рөкүгътан имамнан алда турайса, ул мәкруһ гамәл кыла. Әгәр дә имам артыннан намаз укыган кеше бар рәкәгать дәвамында бар рөкеннәрне дә имамнан алда башкарса, аның ул намазы дөрес булмый. Бу очракта аның моны махсус эшләве яки ялгышуданмы икәне мөһим түгел.

**- Телефон, компьютер һәм башка җайланмаларның экранына Аллаһы исемен кую рөхсәт ителәме?**

- Монда бернинди дә каршылык юк. Әгәр компьютер яки телефон экранында шундый язу торса, аңа саклык вә хөрмәт белән карау тиешле. Андый язуларны экраннарда түгел, ә калебеңдә йөртү хәерләрәк.

**- Корьәнне таһарәтсез килеш компьютердан укырга ярыймы?**

- Компьютер мөсхәф булып саналмый, шунлыктан Корьәнне интернеттан укуда каршылык юк. Әмма Корьәнне уку өчен гөселле булу шарт. Шулай булмаганда Корьәнне хәтердән уку да, шул исәптән компьютер мониторыннан уку да рөхсәт ителми.

*"ШУРА", №7*

# Кукмара мәдрәсәсендә "Мөслимәләр бәйгесе" үткәрелде

**Кукмара мәдрәсәсендә белем алучы хатын-кызлар төркемнәре арасында бәйге үткәрелде. Инде күркәм традициягә әверелгән конкурсның максаты - талибәләрнең белем осталыкларын сынап карау, татар мөслимәләренең рухи тормышын чагылдыру, гадел ярыш мисалында җәмгыятебездә мөселманча яшәү рәвешен популярлаштыру.**



Бәйгедә 3 нче һәм 4 нче курсларда укучы дүрт команда катнашты. "Ихлас", "Ахирәтләр", "Иман нуры" һәм "Яулыклы күңелләр" дип исемләнгән 5 кешелек төркемнәр иң элек "Сәламләү" конкурсында ярыштылар: девизларын әйтеп, команда атамасы асылын аңлаттылыр, үзләре белән таныштырдылар. Соңыннан командалар Коръән уку, вәгазь сөйләү буенча осталыкларын күрсәттеләр.

Татарстан мөселманнарының Диния Нәзарәте тарафыннан 2015 ел "Татар дин галимнәре елы" дип игълан ителү уңаеннан, бәйге программасына милләтебезнең дини зыялыларына багышланган бүлек тә кертелгән иде. Анда төркем вәкилләре тарафыннан Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин, Ә.Максуди һәм К.Насыйри турында мәгълүмат җиткерелде.

Тамашачылар игътибарын җәлеп иткән конкурсларның берсе - әхлакый тәрбиягә багышланган театральләшкән тамаша күрсәтү булды. Татар халык авыз иҗаты үрнәкләрен барлап, төрле мәкальләрне әйтттерү, милли табышмакларга җавап таптыру уены да бик күңелле үтте. Бәйгенең иң "тәмле" урыны исә "Уңган хуҗабикәләр" конкурсында чагылыш тапты: командаларның җиләк-җимешләрдән әзерләнгән композицияләре искиткеч матур, үзенчәлекле килеп чыкты.

Шунысын да әйтергә кирәк: программада каралган конкурсуеннар укучыларның шигырь-мөнәҗәт әйтүләре, алып баручыларның кызыклы һәм файдалы мәгълүмат җиткерүләре белән үрелеп барды. Мәдрәсә мөгаллимнәреннән гыйбарәт жюри эшен Татарстан мөслимәләре берлеге рәисе Наилә ханым Җиһаншина җитәкләде. Призлы урыннарны билгеләүдән тыш, "Коръәнне иң оста укучы", "Зирәкләр", "Талантлылар" һәм "Иң уңган-булганнар" номинацияләрендә дә җиңүчеләр тәгаенләнде. Бәйге барышында катнашучыларга сәламләү вә нәсихәт сүзләре белән Кукмара районы мөхтәсибе Зиннур хәзрәт Сәмигуллин, "Ислам динен кабул итүгә 1000 ел" исемендәге мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин мөрәҗәгать иттеләр. Ахырда барлык катнашучыларга иганәчеләр тарафыннан әзерләнгән бүләкләр тапшырылды.





Мәдрәсәдә оештырылган әлеге кызыклы чарадан укучылар да, мөгаллимнәр дә, килгән кунаклар да бик тә канәгать калдылар. "Бәйге көндәшлекне, үзара ярышуны максат итеп куйса да, дөреслектә ул безне берләштерде, дуслаштырды, рухи мәгънәдә якынайтты. Иң мөһиме - барыбыздан да Аллаһ разый булсын, ә бүгенге чара Аңа якынаюга, әҗер-савапларыбыз артуга сәбәп булсын", - дип әйттеләр катнашучылар саубуллашканда.




*Ришат КУРАМШИН, Кукмара мәдрәсәсе директоры.*





# БЕРДӘМЛЕКТӘ – КӨЧ!

**Эш кайнап тора Буа мөхтәсибәтендә. Менә хәзер дә - балаларның язгы каникулы алдыннан мәш килеп "Минем авылым мәчете" проекты презентациясен уткәрмәкче булып йөрүләре. "Мәчетләренең ничек төзелүе, имамы, мәхәлләсе турында иҗади эшләргә балалар арасында бәйге игълан иттек. Мөхтәсибәттән кыйммәтле бүләкләр дә булачак", - ди Буа мөхтәсибе Илмир хәзрәт Хәсәнов.**





Хәзрәт үзе Буа шәһәрендә туып үскән егет, Россия Ислам институтында шәригать һәм гарәп теле белгечлеге алды, аннары Мәскәүдә юристлыкка укып кайтты. 2014 елның гыйнварында имамнар җыелышында аны бертавыштан шушы вазифага сайлап куйдылар. Кыска гына вакыт эчендә хәзрәт үзе шикелле актив мөселманнардан шәп команда туплады. Районның барлык мәчетләрен йөреп чыгып, һәрбер имамның эше белән танышканнан соң ул үз алдына мәхәлләләрне берләштерергә дигән максат куйды. Рөстәм хәзрәт Хәйбуллин тарафыннан башланган эшне - бар район мәчетләрен һәм аларның җирләрен документлаштыруны төгәлләде, имамнарны үз эш урыннарында рәсми рәвештә теркәтте.

Буа шәһәрендә мәдрәсә һәм биш мәчет - барлыгы алты мәхәллә бар. Аларның барысында да азан әйтелә, намазлар, җомга вәгазьләре укыла. Моннан тыш өчесендә атна саен кичләрен өстәмә вәгазьләр оештырыла. Мәдрәсәдә һәм Абдулмалик, Госман мәчетләрендә намазга, Изге Коръәнне өйрәнергә теләүчеләр өчен укулар бара. Бүгенге көндә белем алучыларның саны өч йөздән артык.

Уку-укыту эшләренә зур игътибар бирелә бирелә. Узган ел рамазан аенда ДУМ РТ һәм РИИ ярдәме белән Казаннан коръәнхафиз кайтарттылар. Ул ай дәвамында балаларга сүрәләр ятлатты. Хәзерге вакытта мәдрәсә коръәнхафизы Абдулла хәзрәт балалар белән шөгыльләнә, абыйстайлар белән Коръән хәтем итә. Узган көз мәдрәсәдә олылар өчен дә дәресләр оештырылды. Мөхтәсиб Казаннан укытучылар кайтартып, алар гарәп теле, Коръән сүрәләре тарихы буенча имамнарга дәресләр бирде. Бу тәҗрибәне дәвамлы итәргә җыеналар.

Соңгы елларда бик популярлашып киткән викторина уенныннан да читтә калмый буалылар. ДУМ РТның "Зәкят" хәйрия фонды белән берлектә өч авылда - Килдураз, Суыксу, Чәчкапта шундый бәйгеләр үтте. Анда мәктәп балалары катнашып, ислам дине нигезләрен яхшы белүләрен күрсәттеләр. Читтә оештырылган бәйгеләргә дә йөриләр, узган ел Түбән Новгород өлкәсенең Сафаҗай авылында, Болгарда, Казан һәм Чистай шәһәрләрендә оештырылган интеллектуаль ярышларда катнашып, барысында да призлы урыннар яуладылар.





Дини чараларны оештыруда, район яшьләре арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауда Илнур хәзрәт җитәкчелегендәге волонтерлар хәрәкәте ярдәм итә. Шәригать кануннарына туры китереп (ир-ат һәм хатын-кызларга аерым), заманча ял итү, күңел ачу, волейбол уйнау, бассейнга йөрү һәм мастер-класслар да оештырыла мөхтәсибәттә. Чаралар хакында алдан смс-хәбәр тарату Мөслим хәзрәт өстендә. Күптән түгел генә контактта "Буа мөхтәсибәте" төркемен ачтылар, андагы яңалыклар өчен Шамил хәзрәт җаваплы. Ул шулай ук районның бөтен авылларына тарату өчен ай саен төрле төстәге дизайнда А-3 һәм А-5 форматларында намаз вакытлары чыгара. Атнага бер мәртәбә җомга саен җирле телевидение каналында инде күпләр яратып өлгергән "Минем динем" исемле тапшыру бара, аның оештыручысы - Марат Хәйбуллин. Мөхтәсибәтнең бар документ эшләрен мөхтәсибнең уң кулы Габдерәхим хәзрәт алып бара. Зиратларны карап, тәртиптә тоту Фәһим хәзрәт Сөләйманова йөкләнгән.



Буа шәһәре өчен **Март** аена намаз вакыты 2015

| Милади 2015 | Атна исеме | Сәхәр тәмам | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Зәвәл | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ясту намазы | Һиҗри 1436 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Якш | 04:37 | 05:07 | 06:37 | 11:59 | 12:15 | 15:25 | 17:21 | 19:00 | 10 |
| 2 | Дүш | 04:35 | 05:05 | 06:35 | 11:59 | 12:15 | 15:27 | 17:23 | 19:02 | 11 |
| 3 | Сиш | 04:32 | 05:02 | 06:32 | 11:58 | 12:15 | 15:28 | 17:25 | 19:04 | 12 |
| 4 | Чәр | 04:30 | 05:00 | 06:30 | 11:58 | 12:15 | 15:30 | 17:27 | 19:06 | 13 |
| 5 | Пән | 04:27 | 04:58 | 06:28 | 11:58 | 12:15 | 15:32 | 17:29 | 19:08 | 14 |
| 6 | Җом | 04:25 | 04:55 | 06:25 | 11:58 | 12:15 | 15:34 | 17:31 | 19:11 | 15 |
| 7 | Шим | 04:22 | 04:53 | 06:23 | 11:57 | 12:15 | 15:35 | 17:33 | 19:13 | 16 |
| 8 | Якш | 04:20 | 04:50 | 06:20 | 11:57 | 12:15 | 15:37 | 17:35 | 19:15 | 17 |
| 9 | Дүш | 04:17 | 04:48 | 06:18 | 11:57 | 12:15 | 15:39 | 17:37 | 19:17 | 18 |
| 10 | Сиш | 04:14 | 04:45 | 06:15 | 11:57 | 12:15 | 15:40 | 17:39 | 19:19 | 19 |
| 11 | Чәр | 04:12 | 04:43 | 06:13 | 11:56 | 12:15 | 15:42 | 17:41 | 19:21 | 20 |
| 12 | Пән | 04:09 | 04:40 | 06:10 | 11:56 | 12:15 | 15:44 | 17:43 | 19:23 | 21 |
| 13 | Җом | 04:06 | 04:38 | 06:08 | 11:56 | 12:15 | 15:45 | 17:45 | 19:25 | 22 |
| 14 | Шим | 04:03 | 04:35 | 06:05 | 11:56 | 12:15 | 15:47 | 17:47 | 19:27 | 23 |
| 15 | Якш | 04:01 | 04:33 | 06:03 | 11:55 | 12:15 | 15:49 | 17:49 | 19:29 | 24 |
| 16 | Дүш | 03:58 | 04:30 | 06:00 | 11:55 | 12:15 | 15:50 | 17:51 | 19:32 | 25 |
| 17 | Сиш | 03:55 | 04:28 | 05:58 | 11:55 | 12:15 | 15:52 | 17:53 | 19:34 | 26 |
| 18 | Чәр | 03:52 | 04:25 | 05:55 | 11:54 | 12:15 | 15:54 | 17:55 | 19:36 | 27 |
| 19 | Пән | 03:49 | 04:22 | 05:52 | 11:54 | 12:15 | 15:55 | 17:57 | 19:38 | 28 |
| 20 | Җом | 03:46 | 04:20 | 05:50 | 11:54 | 12:15 | 15:57 | 17:59 | 19:40 | 29 |
| 21 | Шим | 03:43 | 04:17 | 05:47 | 11:54 | 12:15 | 15:58 | 18:01 | 19:43 | 1 |
| 22 | Якш | 03:40 | 04:15 | 05:45 | 11:53 | 12:15 | 16:00 | 18:03 | 19:45 | 2 |
| 23 | Дүш | 03:37 | 04:12 | 05:42 | 11:53 | 12:15 | 16:01 | 18:05 | 19:47 | 3 |
| 24 | Сиш | 03:34 | 04:10 | 05:40 | 11:53 | 12:15 | 16:03 | 18:07 | 19:49 | 4 |
| 25 | Чәр | 03:31 | 04:07 | 05:37 | 11:52 | 12:15 | 16:04 | 18:09 | 19:52 | 5 |
| 26 | Пән | 03:28 | 04:05 | 05:35 | 11:52 | 12:15 | 16:06 | 18:11 | 19:54 | 6 |
| 27 | Җом | 03:25 | 04:02 | 05:32 | 11:52 | 12:15 | 16:07 | 18:13 | 19:56 | 7 |
| 28 | Шим | 03:22 | 04:00 | 05:30 | 11:52 | 12:15 | 16:09 | 18:15 | 19:59 | 8 |
| 29 | Якш | 03:19 | 03:57 | 05:27 | 11:51 | 12:15 | 16:10 | 18:17 | 20:01 | 9 |
| 30 | Дүш | 03:15 | 03:54 | 05:24 | 11:51 | 12:15 | 16:12 | 18:19 | 20:04 | 10 |
| 31 | Сиш | 03:15 | 03:52 | 05:22 | 11:51 | 12:15 | 16:13 | 18:21 | 20:06 | 11 |

Джумад аль-аваль ае 1436
Джумад аль-ахир ае 1436



Хөрмәтле дин кардәшләр!
Буа мәдрәсәсенең яңа бина төзелеше сезнең ярдәмгә мохтаҗ.
Бу изге эшкә үз өлешегезне кертә аласыз
Р/с 40703810801099000038 к/ч 30101810000000000805
ИНН 1614004168 БИК 049205805 ОАО "АК БАРС" Банк
Белешмәләр өчен телефон:
89276735357. 3-70-71
Изгелекләрегезне Аллаһ Тәгалә кабул итсен!

"Бердәмлектә - көч! - ди Илмир хәзрәт. - Бергәләшеп, аңлашып, ярдәмләшеп эшләгәндә күп нәрсәләргә ирешергә була. Олы рәхмәтемне эшләребездә һаман ярдәм итеп торучы район башлыгы Азат Айзатулловка, аның беренче урынбасары Илдар Еремеевка һәм социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Лилия Садретдиновага җиткерәм. Шулай ук Буа мөхтәсибәтенең хәйрия фондына матди ярдәм күрсәткән оешмаларга да рәхмәт. Барлык чараларны Буа мәдрәсәсендә уткәрәбез, аның директоры Рәшит Маликов безнең һәр чараны хуплап, ярдәм итеп тора... Ә проблемаларга килгәндә, авылларда укымышлы дин әһелләре җитми. Имамнар картая, аларга алмаш кирәк. Мәхәлләләр үзләренең имамнарын кайгыртып, аңа ярдәм итеп яшәсәләр, бу хәл итә алмаслык нәрсә түгел, иншә Аллаһ".

***Лилия ВӘЛИУЛЛИНА***

# "ИЛНЕҢ ИҢ ЮГАРЫ МӨНБӘРЕНӘ МЕНГЕЗГӘН ХАЛКЫМА РӘХМӘТ"

**Казан Кремлендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов Бөек Ватан сугышы ветераннарына тантаналы рәвештә "1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгы" юбилей медален тапшырды.**



- Медаль алучылар барыбыз 40 кеше идек. Барыбыз да сугышта катнашучылар, арабызда бер Герой да бар, Кузнецов. Дүртенче кеше булып алдым юбилей медален, - дип башлады сүзен Фәйзи Әхмәт улы Галиев.

Мөхтәрәм аксакал Әтнә районының Түбән Шашы авылында улы Тәлгать белән килене Суфия тәрбиясендә яши. 17 яшеннән фронтка китеп, аерым Идриц исемендәге Кызыл Байраклы 219 нчы укчы дивизиясе составында Смоленск шәһәрен азат итүдә катнаша һәм шунда авыр яралана, шул көннән бирле күкрәгендә фашист снарядының кыйпылчыгын йөртә. 19 яшендә, 1944 елда, колхоз рәисе итеп билгеләнеп, 50 ел дәвамында туган җирендә җиде авылны берләштергән "Искра" колхозын җитәкли. Гомере буе туган төбәге халкына хезмәт итә, шул халык аның үзен дә Россия күләмендә таныта. Лаеклы ялга чыккач, үзе күргәннәрне язып, 5 китап чыгара, алтынчы китабының нәшрияттан кайтуын көтә Татарстан Язучылар союзы члены.

- Сәхнәгә менгәч, Президент белән күзгә-күз карап елмаештык, күз белән аңлаштык, аркамнан сөеп, үз итеп, тирән хөрмәт белән "Фәйзи абый", дип эндәште. Бу минем Рөстәм Нургали улы кулыннан беренче тапкыр гына бүләк алуым түгел. Элегрәк сугышта катнашучыларга машина бирделәр, миңа да әйттеләр. "Үзебезнекеләр алып бетермичә торып, миңа тиешле машинаны алмыйм", - дидем. Берсе генә калгач бардым, машинага чиратка куеп көтәргә куштылар. Шунда бер яшь егет тә басып тора иде, ул чыгып китте. Коридорга чыккач: "Фәйзи абый, машина кирәк мәллә?" - ди. "Кирәк иде шул, чират икән", - дим. Иртәгесен миңа шалтыратып: "Сезгә машинаның нинди төслесе кирәк?" - дип сорады да, барып, машинаны сайлап алырга кушты. Шулай итеп, машина алып кайттым. Бу егет Рөстәм Миңнеханов булып чыкты, ул вакытта райпотребсоюз системасында эшләгән чагы. Мин аңа шул вакыттан бирле рәхмәтле.



... Костюмына Президент үзе беркеткән бу медаль янәшәсендә башкалары да җитәрлек: Ленин ордены, ике "Хезмәт Кызыл Байрагы" ордены, Татарстанның иң югары бүләге - "Татарстан республикасы каршындагы казанышлары өчен" ордены, "СССР Хәрби көчләренә -70 ел" медале... Санап бетергесез. Медальләр янәшәсендә "РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре", "Татарстанның атказанган агрономы", "Гвардия солдаты" билгеләре.

- Исем белән медальләрнең исәбе юк инде, алардан тыш мин - "Почетлы колхоз рәисе", "Почетлы пионер" да әле. Аллага шөкер, кулдан килгәннең барысын да эшләдем, иң мөһиме минем эшләгән хезмәтемне күрә белделәр, Россиянең иң югары мөнбәренә менгезгән халкыма мин бик рәхмәтле һәм алар алдында баш иям, - ди Фәйзи абый авылдашларына тирән хөрмәт белән. Өстәп куя:
- Эшләп була, тик берәрсе туган җирендә авылдашлары каршында минем кебек эшләп карасын. Бу - зур сынау, Аллага шөкер, намусым ак.

Коры сүзләр генә түгел болар. Фәйзи абый эшләгән 50 ел эчендә 16 беренче секретарь, 16 авыл хуҗалыгы министры алышынган. Берсеннән- берсе кырыс таләпләр куелган колхозларга, ә дәүләт планнарын үтәргә кирәк. Һәр тармакта алдынгы булгач, Фәйзи Галиев җитәкләгән "Искра"га үзләренчә эшләргә рөхсәт бирәләр. Үз алдына максат куеп эшләүче җитәкчене колхоз күрсәткечләре генә түгел, сугыш чоры, сугыш арты авырлыкларын бергәләп күтәргән авылдашларының яшәеше дә борчый. Ул елларның бер генә көнен дә, бер генә газабын да онытмый ул, шуңа күрә үзенең кул астында эшләүчеләрнең тормышын, көнкүрешен җиңеләйтәсе килә. 1985 елда (!) колхоз хисабына 3,5 миллион сумга 7 авылда яшәүчеләрнең өйләренә бушлай газ кертә.

Әтнә районында гына түгел, республикасында да бул-



магандыр "Искра" кебек хуҗалык ул елларда, ә аның халык турында кайгыртучы җитәкчесе - бердәнбер. Мин дә хәтерлим, мәктәптә укыган чак, авыл шаулый: "Фәйзи авылларга газ керткән, бәхетлеләр яши бу "Искра"да". Олылар авызыннан ишеткән андый рәхәт тормышны күз алдына да китерә алмадык без ул чакта: ничек инде утын, ташкүмер якмыйча өй җылытып булсын ди! "Бу акчага ул вакытта 270 "КамАЗ" машинасы алып була иде", - ди Фәйзи абый. Машиналар да бик кирәк, әмма аның өчен төп байлык - кешеләр, авылдашлары булган шул.

Халык өчен эшләгән җитәкче үзе дә онытылмый, еллар узган саен кадере арта гына бара. Ул ачлыктан алып калганнарның балалары, оныклары исән, буыннар хәтере дә мәңгелек. "Урамга чыкмасам, шалтыратып хәлемне сорашалар, ярдәм кирәкмиме, дип сорыйлар, ә минем шатлыктан күземә яшь килә. Хөрмәт билгесе бит бу", - ди Фәйзи ага. 50 ел җитәкчелек иткәндәге изгелекләре менә шулай игелек булып кайта хәзер.

- Миннән гел: "Кайдан аласын акча?" дип сорадылар. "Җирдән", дип җавап бирә идем. Ә көчне гаиләмнән алдым. Эчмәдем, тартмадым. Күбрәк җәяү йөрергә тырыша идем. Хатыным Сара да бик әйбәт булды. Әгәр Сара кебек эшчән, булдыклы хатыным булмаса, балаларыбызны ул тәрбияләп үстермәсә, мин эшләгән эшләремнең яртысына да ирешә алмаган булыр идем. Минем тылым ышанычлы булды, гомер буе өемә кайтасым килеп кайттым. Үземнең кадерле икәнемне белеп яшәдем. Бик тату гомер кичердек. Кышын чаңгыда шуар идек, җәен табигатькә соклана белдек... Бик акыллы, бик чибәр иде, бик сагынам Сарамны", -ди Фәйзи абый күз яшен сөртеп.- Балаларым Фаил, Фаилә, Тәлгать тә камил фикерле, әниләренең математик булуы нәтиҗәсе бу, дөньяның нинди икәнен, кай якка барганын чамалый беләләр. Һәркайсы тормышта үз урыннарын таптылар, гаилә корып балалар үстерәләр. Аларга да рәхмәтем зур, мин әле дә бик кадерле, нәрсә теләсәм шуны эшли алам, Аллага шөкер, өстем чиста, тамагым тук. 10 оныгым, 6 оныкчыгым бар. "Бабай", "Дәү әти" дип кенә торалар. 90 яшемә якынлашам, анысын күреп булырмы, гомер Аллаһы кулында . Минтимер Шәрипович: "Бергәләп бәйрәм итәбез әле 90 яшеңне", - ди. Хөкүмәт җитәкчеләре дә шулай дип сөендерәләр. Бу - хөрмәт, миңа гына түгел, минем авылыма мөнәсәбәт".

Мондый бәхетне туган җирдә тамыр җибәргән кеше генә татый ала. Туган йортта кадерле булу өчен дә иң элек үзең кадерли белү кирәк. Язылмаган законнарны үтәүнең әҗере бу.

Туган авылы, кендек каны тамган нигез Фәйзи абый өчен аеруча кадерле: ул - әдәп-әхлак һәм гореф-гадәтләребезне, рухидини-мәдәни традицияләребезне саклаучы изге урын да, күңел сандыгын баетучы да. Фәйзи Әхмәт улы, шушы нигезгә лаек булып яшәп, киләсе буыннарга искиткеч зур хәзинә туплаган. Аның архивында - авыл, колхозның үткәне, кешеләре, яшәеше, оешуы, гореф-гадәте. Бер авыл белән генә чикләү дә дөрес булмас, Татарстан тарихы бу. Аларны актарып, һәр документны кулга тотып карагандагы кичерешләрне тасвирлап та булмый, шатланасың да, горурланасың да. Пөхтәләккә исең китә, сугыштан әнисенә язган хатларны Фәйзи абый бергә туплап теккән. Икенче төргәктә - блокнотлар. Бер блокнотта - колхозның берьеллык күрсәткечләре, монда бар да бар, күпме керем, күпме чыгым, ничә белгеч эшләгән, тракторчылар ничәү, кем ничәнче класслы, сыер савучылар күпме, кемгә күпме түләнгән, һәркем, һәр тиен исәптә. Һәр ел өчен бер блокнот тутырылган. Менә кайда ул тәртип, намус, йөз аклыгы. Ул фотоларның иге-чиге юк. Һәр фото да - бер тарих.

- Менә бу - минем беренче секретарем Сабир Шакиров. 1944 елны 19 яшьлек егетне райкомга чакырып, колхоз председателе итеп куйган кеше. 50 яшем тулганда чакырдым үзен, кочаклап елады: "Бар икән мине дә искә алучы кеше, рәхмәт, энем,"- диде. Ул мине олы тормыш юлына чыгаручы беренче кеше. Вакыт-вакыт исемә төшсә, үземә дә куркыныч булып китә: 6 центнер уңышлы, 120 сарыклы, 45 сыерлы, банктагы счетында 140 сум акча бар, анысы да счет ябылмасын өчен тора, амбарында бернинди азык юк. 80 кешесе шешенгән - миңа мирас булып күчкән байлык шушы. Мәктәп залына салам җәеп, күтәрәмгә калган сыерларны аякка бастырып, чирәмгә чыгарабыз, азрак ашый башлагач, сыерлардан сөт савып, умач уып, мәктәптә ике мәртәбә ашатып аякка бастырдык 80 кешене. Урамнан бер малай бара, азрак бара да егыла. Ник егыла икән бу малай, дим. Мәктәп кырыенда малайлар уйный, бу шунда барырга чыккан, ашамагач хәле юк, шуңа егыла икән. Менә шуннан соң малайларны өлгергән арышка куып чыгардык, яннарына каравылчы куйдык. Берәр вәкил килсә, малайларны яшерергә анысы. Менә шулай саклап калдык малайларны. Бу - бөек эш, менә шул кешеләр соңыннан мине күтәрделәр. 32 тапкыр депутат булып сайланган кеше мин... - дип сөйли Фәйзи ага. Фикере ачык, әзлекле. Хәтере уникаль, бөтенесен төгәл числоларына кадәр хәтерли, документлар белән дәлилли. Һәр кешене зур ихтирам белән искә ала. Һәр җитәкчегә үз фикере, үз мөнәсәбәте. - Иң начар кешенең дә бер уңай ягы була, әнә шуны үстерә белергә кирәк.

Ул сөйли, мин сокланып тыңлыйм. Туган җирен яраткан кеше генә дөньяны шулай ярата ала торгандыр. Фәйзи абыйның йөрәгенә бөтен дөнья сыйган.

***

Фәйзи ага фронттан әнисенә язган хатларын теркәп барган. "Дин вә мәгыйшәт"нең бүгенге сәхифәсендә укучыларыбыз игътибарына шуларның кайберләреннән өзекләр тәкъдим итәбез.


ДЕЛО

**"Кадерлеләрем сезгә сәлам хат**

***12.VIII.1943***

Иң кадерле күргән әнием, сиңа һәм ике энем Фирдәвес һәм Рубискә бер нәрсәләргә дә тиңе булмаган яшь йөрәгемнән кайнап чыккан сәламнәремне сезнең якларга җибәрәм. Шулай ук миннән әбигә, Хади абыйга, Кәшфә апайга, Фәйзрахман абыйга, Фәсәхәт җизнигә бигрәк тә күп итеп сәламнәр юллыйм.

Без 11 е көнне Ярославль шәһәреннән чыгып киттек. Безнең барасы җир билгеле инде, аны сезгә әйтеп торуның кирәге юк. Шулай итеп, яшь йөрәкнең батырлыгын сынап карау өчен барабыз. Безнең белән Саба, Теләче, Чепья, Питрәч татарлары да бар. Аннан алты мари бар. Сезгә теләгем шул. Исән-имин була күрегез".



***

**"Исәнмесез кадерле туганнар Сагынычлы сәлам**

***1943 ел.***

Дөньяда иң кадерле булган әнием, сине, ике энем Фирдәвес белән Рубис, сезне сагына-сагына хат язам. Шулай ук мине сораганнарга бик күп сәлам. Әни, әлегә без фронт сызыгыннан 100 километр артта. Минут саен хәбәр көтеп торабыз. Хәл пока зарланырлык түгел. Ашау-эчүләр дә әйбәтрәк. Әни, әллә ниләр яза алмыйм, эч поша, пока исән вакытта шуны әйтеп каласым килә, бәрәңгеләрне алып бетерә күр инде, бәрәңге белән яшәргә була.

Әни, акча салдым, дип язгансың, моннан соң миңа бер тиен дә җибәрәсе булма. Әни, мин сезне төштә күреп тә кайгырам, ничек итеп бакча эшләрен бетерерсез дә, ни хәлләр сукаларсыз инде. Аннан соң, әни, мунчага кечкенә генә мич тә чыгарасы булыр, казан утыртып, шунда аш та, ипи дә пешерә алыр идегез.

Әни, сиңа тормыш итүләре бик авыр инде. Шулай да тырыша күр, мин моннан сиңа берни дә ярдәм итә алмыйм. Әни, зинһар дип әйтәм, әйберләрне утынга якма, кәнсәләргә төшеп елап йөри күрмә".



***

**"Исәнмесез кадерле туганнарым!**

***7/XI-1943***

Байтактан бирле армия сафларында хезмәт итеп, Советлар Союзының хезмәт иямләрен гитлер тырнагы астыннан азат итү сугышында ранен булган абыегыздан сагынычлы сәлам. Үзем тазарып киләм инде. Миңа хат язганда авыл хәлләрен күбрәк языгыз. Әни, мин үзем аз хезмәт итсәм дә, күп күрергә туры килде. Исән кайтып, шуларны сезгә дә сөйлисем килә..."

***

"... Мин 11/IX көнне дошман снаряды осколкасыннан ранен булдым. Сул кулбашына алгы яктан сөякне ватып кереп, борчак кадәр осколкасы икенче якка тишеп чыгып җитә алмыйча шунда калды. Ярам бик зур иде. Хәзер инде чисти тазарып җитеп киләм. Әүвәл бармаклар эшләми, кул күтәрелми иде. Госпитальдә өч ай яттым. Баштарак чулак булып каласың дип куркытканнар иде, бик ихластан лечить иттеләр. Әни. Минем ранен булуны бик сөйләп йөрмәгез. Алла бирса, кайчан да булса, исән кайтырмын дип үземне юатам..."

*Сәхифәне*
***Сурия МИНГАТИНА***
*әзерләде*





**Илләр арасында сәяси мөнәсәбәтләр суынып китсә дә, сылу затларыбыз хатын-кызларга карата ирләрнең нечкә күңелләренең суынасы юк. Соңгы елларда күп хатынлылык тирәсендә шактый бәхәсләр бара. Әлеге мәсьәләне берничә ел элек Ингушетия башлыгы Руслан Аушев күтәреп карады, ниләр генә ишетмәде. Жириновский да ирләрнең каннарын бераз кыздырып алды. Рамзан Кадыйров та вакыты-вакыты белән утка утын өстәп тора. Гадәттә, ирләр аның ише хәбәрләрне ишетеп, тыныч кына авыр сулап куялар, хатыннар ирләренә карап: "Хәзер менә", - дип йодрык күрсәтәләр. Кыюлыгымны туплап, әлеге четерекле мәсьәләне мин дә күтәрергә уйладым. Беләм, язмамны укыган ханымнарның күбесе мине мактап кул чапмаслар. Шулай да, язмышында ялгызлык ачысын татыганнары эчтән генә рәхмәт сүзләре дә әйтер, дога да кылыр диген өметем юк түгел. Әлеге эштә шәхси тәҗрибәм булмау сәбәпле, фикерләремне туплау өчен тәҗрибә ияләре белән дә аралашырга туры килде. Һәрхәлдә, гамәлемне кеше ризалыгын алу өчен түгел, Раббымның рәхмәтенә ирешү өчен башкарам, Үз ярдәменнән ташламасын.**

# СӘЛАМӘТ ИРГӘ БЕР

**КАЙВАКЫТ,** күп хатынлылык темасы күтәрелсә, ханымнар: "Бу мужикларның башында гел шул", - диләр. Ирләрнең сылу затларга булган хисләрен хатын-кызлар беркайчан да аңлый алмаслар. Без дә кайчак, хатыннарның алтын кибетләренә кереп, нинидидер сары тимер, ялтыравык ташларга мөкиббән китүләрен күреп аптырыйбыз. Нишлисең, Раббым һәркемгә үзенең нечкә якларын биргәндер инде. Чыннан да, төсле тимер яки ташка гашыйк булуга караганда хатын-кыз зәвыгының әсире булуны аек акыл тизрәк аңлый. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: "Куркыгыз дөньядан һәм хатын-кыздан", - дип, хатын-кызның ирләргә булган тәэсирен тиктомалдан гына искә алмады. Сылу затлар әллә нинди көчле дәүләтләр белән идарә итүчеләрнең башларына җитәләр, әллә нинди баһадирларны аяктан егалар. Шуңа күрә, әгәр бер ирне хатын-кыз мәсьәләсе борчымаса, димәк, ул ир яки авыру, яки бөтенләй ялгыш якка юнәлгән. Андыйларын да алда искә алып китәрбез.

## Күп хатынлылык әмер түгел

Иң элек динебездә күп хатынлылыкның әмер түгел, рөхсәт эш икәнен аңлап китик. Кыямәттә Аллаһ бер ирне дә: "Ник бер хатын белән генә яшәдең", - дип шелтәләмәс. Ислам саранча ашауны да хәләл ди, ләкин, бу әйдә бөтенегез басукырлардан саранча җыйыйк, дигәнне аңлатмый. Әмма кайсыдыр заманда, җирнең кайсыдыр бер почмагында мөселман халкына саранча ашарга туры килергә мөмкин, хәер, "бисмилләсен" әйтеп ашый ала. Әгәр чиксез хикмәт иясе Аллаһ ир кешегә берничә хатынны хәләл кылган икән, димәк, моның сәбәбе, хикмәте бар. Бәлки, кайчандыр, кайдадыр, нәкъ күп хатынлылык кешелекне, милләтне саклап калуның бердәнбер чарасы булыр. Бөек Ватан сугышында, Рәсәй һәм алман халкы үзенең күпчелек ир затларын югалткач, билгеле, демографик кризис туа. Халыкны саклап калу, яшь буыннарны булдыру мәсьәләсе беренче планга чыга. Бу хакта Германия дә борчыла һәм зур конференцияләр оештырып, анда күп илләрдән галимнәр катнаша. Шуларның берсенә Мисыр университетыннан да галимнәр килеп, алар исән калган ирләргә икенче хатын алуны рөхсәт итәргә тәкъдим итәләр. Әлбәттә, күпчелек моңа каршы чыга, шулай да, илнең кайбер шәһәрләрендә, вакытлыча булса да, ирләргә икенче хатынга өйләнүне рөхсәт итәләр. Шунысын да белик: күп хатынлылыкны кабул итмәгән шәһәрләрдә фахишәлек рәсми рәвештә рөхсәт ителә. XVII гасырда да шул ук Германиядә католиклар белән протестантлар арасында 30 ел сугыш барганнан соң, халык саны 17 миллионнан 4 миллионга кала. Хөкүмәт халык санын тутыру өчен 10 елга ирләргә икенче хатын алырга рөхсәт бирә. Европа исламдагы күп хатынлылыкның кешелекне саклап калуда булган олуг файдасын берничә мәртәбә танырга мәҗбүр була.

Әлбәттә, исламны "кеше өчен агу" итеп күргән совет иле күп хатынлылыкны кабул итә алмады, сәвит хатынын "кимсетергә" юл куймады. Әмма Рәсәй ирләре күп хатыннардан беркайчан да баш тартырга ашыкмадылар. Шуңа күрә безнең илдә дә рәсми булмаган күп хатынлылык борынгыдан яшәп килә. Ирсез, тол калган бичараларны ничек игътибарсыз калдырасың инде?

Авылга имам булып кайткан елны мине бер җеназага алып киттеләр. Машинада өч колхоз рәисе белән гәпләшеп барабыз, кинәт берсе: "Хәзрәт, диндә тол хатыннарның күңелен күрү савапмы бит?" - дигән сорау бирде, бөтенесе көлешеп куйдылар. Мин үземнең беркатлыгым белән: "Әйе, элгәре заманнардан ирен югалткан хатын-кызларны кайгырткannнар, аларга ярдәм иткәннәр", - дидем. Җавабым абзыйның күңеленә хуш килде һәм ул: "Менә бит егетләр, нинди изге эш эшлибез икән", - дип, барысы да куанышып куйдылар. Бер-ике ел мулла булып, халык "гадәтләре" белән танышканнан соң гына мин халкыбызның "ятим хатыннарның күңелен күрү" йоласының чын мәгънәсен аңладым.

Бүгенге көндә дә күп кенә Кавказ халыкларында тол хатыннар мәсьәләсе кискен тора. Сугыш-бәрелешләрдә меңләрчә ир затларын югалткан милләтләрне бүген ничек торгызырга? Шуңа күрә Рамзан әнә үзе өчен түгел, халкым, дип тырыша. Ә милләт башлыгы үзе канун үзгәрүгә мохтаҗ түгел, күптән өч хатын белән яши. Уйлап карасаң, Рәсәй җитәкчеләренең күпме акчалары сөяркәләрен тотуга китә. Сөяркә дә кеше, аның да кешечә яшисе килә. Яхшы фатир кирәк, җылы якта ял итәсе дә килә. Кайбер авылларда иренең кайда, кем белән йөргәнен бөтен авыл белсә дә, хатыны гына бернәрсә дә белми, күрми, ишетми яшәвен дәвам итә. Куәте җиткән байларыбыз тәннәрен һәм малларын пычрак юлга тотканчы, икешәр хатын белән никахлашып, аларны тәрбия кылсалар, балаларын үстерешсәләр, Рәсәй халкының тормыш дәрәҗәсе ничә баскычка күтәрелер иде. Бәлки, халык каршында да абруйлары артыр иде.

Бервакыт, чит ил хәбәрчеләре безнең Президенттан: "Татарстанда күп хатынлылык бармы?" - дип сорагач, ул шаяртып кына: "Качып-посып бардыр инде", - дип җавап бирде. Качып-посып күп хатынлылык һәр чорда, һәр милләттә булды. Күпләр өчен изге саналган Ленин бабайның да көндезге кояшы Надежда булса, төнге ае исә - Инесса иде.

## Күп хатынлылыкны ислам алып килмәде

Кайберәүләр күп хатынлылыкны тизрәк ислам белән бәйләргә тырышалар. Янәсе, бөтен дөнья ирләре гасырлар буе хатыннарына тугры булып яшәделәр дә, җир өстенә Мөхәммәд (саллаллаһу галәйһи вә сәлләм) килеп, ирләр күңеленә коткы салды. Күп хатынлылык яһүдләрдә дә, христианнарда да, мәҗүсиләрдә дә булды. Риза Фәхретдиннең язмаларында татарларның исламга кадәр, мәҗүсилек чорында яшәгән ирләрнең ничә хатыны һәм алар ни хәлдә булганын яхшы тасвирлый. Үлгән ир янына, иптәш булсын дип, берәм-берәм хатыннарын да терелэй көе кабергә салуларын җентекләп яза. Бүген дә халкыбызны шул тәңречелек елларына чакыручыларны күреп таң каласың.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм күп хатынлылыкны алып килмәде, ул аны билгеле бер тәртипкә салды. Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм кешелеккә: "Хатын кол түгел, синең тормыш иптәшең. Һәр ир өстендә хатын вазыйфасы тора, Кыямәттә һәркем ул вазыйфасы өчен җавап тота", - дип аңлатты. Хатын-кызның да мираска булган хакын күтәрде. Иң мөһиме: "Араларыңда гадел була алмасагыз, сезгә берәү дә җитә", - дигән аятьне җиткереп, ирләрне гадел булырга чакырды.

## Ир икенчене эзләсә...

Еш кына (һәрвакыт алай түгел), ирнең икенче хатын эзләвенең сәбәбе булып хатын үзе тора. Без ирләр, бераз шапырынырга яратсак та, хатыннардан башка әллә ни булдыра алмыйбыз шул. Хатын балалар белән авылга китсә, берничә көннән киштәдә ни өчендер оекбашлар да, чиста күлмәкләр дә бетеп китә. Баксаң, ул оекбаш салган җиреннән үзе кер юу машинасына керми, балконда кибеп, киштәгә очып менми икән. Күлмәк якалары да үзләре агармый, чалбар стрелкасы да яңармый. Тәмле ашлар да үзләре пешми... Бер бизнесвумен-ханымның ире икенче хатын янына качкач, ул аны: "Үзенең мең долларлык юрган белән ябынганын белми, хайван", - дип сүгә. Ә бит илледән узган абыйга затлы юрган түгел, игътибар-наз җитми. Бәлки абзый кибет пилмәне ашап алҗыгандыр. Бәлки берәрсе: "Әйдә, кил миңа, токмач басып ашатам үзеңә", - дигәндер...

Кызганыч, кайбер хатыннар ирләрне генә түгел, үзләрен дә карамыйлар. Тән пакьлегенә, шәхси гигиенага игътибар бирмиләр. Ирләр, ярар инде, әмма кайвакыт хатын-кыздан тир исе килеп торса, 40 яшьлек хатынның авызында теше булмаса, булмый инде ул, җәмәгать. Булган хатын мөмкин кадәр үзе дә кояш кебек балкырга, нурларын гаиләсенә дә чәчәргә тиеш. Монда мин һәр гаиләгә үрнәк булган Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм белән Хәдичәнең тормышын китерәсем килә. Алар өйләнешкәндә Пәйгамбәребезгә 25, Хәдичәгә 40 яшь була. Алар 25 ел бер тән, бер җан булып яши, утны-суны үтә. Урамда давыл булса да, Хәдичәнең өендә һәрвакыт кояш була. Ул вакытта күп хатынлылык гарәпләрдә киң таралса да, Хәдичәсе вафат булганчы Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм башкага өйләнми. Хәдичәсен җирләп, күпме еллар үтсә дә, аны гел сагына, рухына дога кыла.

## Күп хатынлылык кем файдасына?

Яшь, сәламәт вакытта хатынкызның ирен гел кочагында, гел үз янында тотасы килә. Әмма тормыш бара, балалар туа, иргә вакыт та аз кала. Берсенең керен юарга, икенчесен йоклатырга... Ә иргә хатын-кыз назы кирәк. Күпләр өендә күрмәгән назны шыпырт кына читтән алып кайта. Иманы булган, сулга йөри алмый. Ул нишләргә тиеш? Балалар үсеп, башка чыккач, миңа да чират җитәр әле, дип яшәргәме? Аннан инде яшьлеге дә үтә, бербер артлы онықлар китә... Чират җитмәү сәбәпле, күп гаиләләрдә ир белән хатын арасында низаглар килеп чыга. Ир "вечно" риза түгел, авыз эченнән нидер сөйләнә... Шулвакыт күп кенә хатыннар: "Эх, бу ир ике мәртәбәгә әзрәк булса иде", - дип тә куялар. Ярый элгәре заманнарда ирләр ауда йөргәннәр, сәфәрләрдә булганнар, хатыннары ирләрен сагынып торганнар. Ә хәзер, күп гаиләдә ир көне-төне өйдә, диванда телевизор карап ята. Көне буена бер-берсен сагыну түгел, туеп та бетәләрдер.

Хатын-кызга да кайвакыт, иреннән ял итү файдага китә. Кайбер хатыннар өчен иренең сәфәрдән кунарга кайтмавы үзе бер шатлык. Ашарга әллә нәрсә пешерәсе юк, балаларга макарон белән колбаса да бара. Берәр кичкә бәләкәчләрне әнигә дә җибәреп торырга була. Нәтиҗәдә, иренең төнгә кайтмавы хатын өчен сирәк була торган бәйрәмгә әйләнә.

Гаиләнең иң зур максатларының берсе булып балалар тора. Балалар дөнья тормышының бер зиннәте, күңел шатлыгы. Гаиләдә бала булмау, элгәре заманнардан күп гаиләләрнең таркалуына китергән. Әгәр парларның балалары булмыйча, сәбәбе иренең авыруында булса, шәригать хатын-кызга иреннән талак сорау хакы бирә. Ире хатынын мәҗбүриләп тотарга тиеш түгел. Сәбәп хатында булса, кайбер ирләр алардан аерылып, икенчегә өйләнү хәстәрләгән карыйлар. Гадәттә, хатын-кызның балага уза алмавының хәбәре таралгач, башка ирләр дә андыйлардан ерак тора. Шуңа күрә, борыңгыдан дин әһелләре ирләргә хатыннарын аермаска, гел булмаса икенче хатын алырга киңәш иткәннәр. Бу күп кенә

# ХАТЫН ҖИТӘМЕ?



үз тиңен көтеп картаерга, саргаерга, яки ялгыш юлга басарга кала. Бозык ирнең биш сөяркәсенең берсе булып яшәгәнче, икенче, әмма никахлы чиста хатыны булу хәерлерәк. Чын ирләр дефицит булган саен, алар өчен көрәш тә кызып бара. Бүген гаиләле ирләрне хатыннарыннан аерып үзенеке итүче хатыннарга мисаллар бихисап. Алга таба хәлләр тагын да мөшкел булачак. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: "Ахырзаман алдыннан урам буйлап ир үтәр, артыннан кырык хатын мактап калыр", - диде. Шулвакыт хатын-кызның дәрәҗәсе өчен "көрәшүче" феминистик оешмалар: "Нишләп Коръән бер иргә кырыкны түгел, дүртне генә рөхсәт итә?" - димәсләрме? Күрәселәр алда әле.

Кырык яшендә ялгыз калып, берүзе балалар үстерүче ханымнарыбызның күбесе икенче булып булса да, көчле җилкә артына шатланып керерләр иде. Дагыстан кызлары да социаль челтәрдә ир-егетләргә: "Ялгызлыктан ардык, безне кайчан аласыз?" - дип рәхәт тормыштан мөраҗәгать итмәгәннәрдер. Тормыш шуны күрсәтә: ялгызлыкның нәрсә икәнен таты-

хатын-кызларның ялгыз калмауларына сәбәп булган. Ибраһим пәйгамбәр галәйһиссәлләм күп еллар хатыны Сара белән яшәп тә балалары булмый. Изге нәсел сорап дога кылучы ирен күреп, Сара аңа Һаҗәр исемле хатынны үзе тәкъдим итә. Шулай итеп, Ибраһимның 86 яшендә генә Һаҗәрдән улы Исмәгыйль туа. Берничә елдан Сарага да Аллаһының рәхмәте иңеп, ул да балага уза һәм уллары Исхак туа. Тагын берничә елдан өченче улы Якуп дөньяга килә. Шөкер, Сара иренә хәерле хатын булганы өчен, җәннәт бакчаларында да Ибраһим янәшәсендә мәңге калачак.

## Күпхатынлылык шәһвәт сүндерү генәме?

Кайберәүләр икенче хатынны җенси шәһвәтне сүндерү генә дип уйлыйлар. Никахны гел шул нәрсәгә генә кайтарып калдыру зур гаделсезлек. Моны олыгайган саен ныграк аңлыйсың. Яше илледән узган бер апа: "Яшьләй ирем вафат булды, кияүгә чыга алмадым. Балалар да булмады. Ялгызлык бик авыр. Яши торгач, диндәге күп хатынлылыкның хикмәтен аңлыйсың икән", - дип сөйләде. Һәр хатынкызның көчле җилкә артында яшисе, кичен кемнедер көтәсе, кем өчендер пешеренәсе, бергәләп чәйләр эчәсе килә... Егерме ничә яшендә ирен югалткан бер ханым да, икенче хатын булып кияүгә чыккач: "Элек киләсе айда фатирга ничек түләргә, балага ничек кышкы аяк киеме алырга, дип борчыла идем. Хәзер андый кайгыларым калмады", - дип сөйләде.

Күп хатын-кызлар минем белән килешергә теләмәсләр, әмма ислам рөхсәт иткән күп хатынлылыкның төп авырлыгы ир җилкәсенә төшә. Һәр рәхәтнең үз михнәте була, диләр. Гадел булыйм, дигән ирләр атна көннәрен сменаларга бүлеп, ике арада чабып йөриләр. Ике хатынның нәрсә икәнен аңларга өлгергән бер дустым: "Хәзрәт, әгәр хатыныңа атнасына 20 мәртәбә "матурым" дисәң, 50 мәртәбә кочакласаң, 40 мәртәбә үпсәң, икенчене алгач, шул ук эшне ике мәртәбә күбрәк эшләргә туры килә. Чөнки, беренчесеннән икенчесенә килеп, анысы әзерләнеп каршы алганда: "Матурым, мин сине кичә генә үпкән идем бит әле", - дип җиңел генә котылып булмый. Күрмәгәннең күрәсе, күргәннең качасы килә, дигәне шушы инде. Әле сәламәт көндәшлек мәйданында хатыннар да йокыдан уяналар. Кайсы хатынның көрәштә байракны башкага бирәсе килсен? Кыскасы, Аллаһ ярдәменнән ташламасын, ике хатын белән яшәү, җиңел эштер дип уйламыйм. Әтәчкә үз кетәклегендә күпкә җиңелрәк, тавыклары күп булса да, аның тещалары юк. Хатын икәү булса, ике теща каршында җавап тотарга туры килә. Кайвакыт, бер хатын белән дә өйдә күк күкри, яшен яшьни, җырләр тетри... Икәүләшеп тотынсалар нишләмәк кирәк? Бер танышым: "Хәзрәт, хатыннарым шулкадәр дуслаштылар, миңа каршы байкотны да бергәләшеп игълан итәләр", - ди.

## "Гадел булмам дип курыксаң, берәү дә җитә"...

Аллаһы тәгалә Коръәндә ирләргә дүрт хатынга кадәр алырга рөхсәт итте, әмма аятьнең ахырында: "Араларында гадел булмам, дип курыксагыз, сезгә берәү дә җитә", - дип кисәтте. Гадел булу өчен ир кешегә ай-һай күп тырышырга кирәк. Әтәчнең тавыкларына бер кетәклек тә җитсә, монда һәркайсына аерым торак кирәк. Бүгенге фатир бәяләре белән берсен тәэмин итә алсаң да зур шатлык. Әлбәттә, фатирлысын да табарга була, әмма гаделлек торакта гына гына түгел ич. Кичләрәкне тигез итеп бүл, берсенә бүләк алдың, икенчесенә кая? Берсе белән чит илдә ял итеп кайттың, икенчесен дә алып бар. Берсе белән биш йолдызлыда, икенчесенә ике йолдызлысы ярамый. Бөтен балаларны укытырга, киендерергә, теш табибына алып барырга... Төн уртасында икенче хатының авырып шалтыратса, чыгып чабарга кирәк. Ярар, ул кадәр катлауландырма инде, дияр кемдер. Катлауландырмый булмый шул, дөньяда бу нәрсәләргә җиңел карасаң, авырлыгы ахирәттә башыңа төшәчәк. Кыямәт көнендә Аллаһ каршына килеп баскач, бер хатының гына синнән зарланырга тотынса, ничек тә котылырсың, ә икенчесе, өченчесе килеп кушылса, нишләрсең? Шуңа күрә, кинодагы мәшһүр җыр: "Әгәр мин солтан булсам, минем өч хатыным булыр иде", - дип башланса да, ахыр юлы: "Аллаһ сакласын", - дип бетә. Күпвакыт, берничә гаиләне тартырга хәленнән килгән егетләр, җаваплылыктан куркып, ул эштән тыелалар. Ә кайберләре бер гаиләсен дә кешечә яшәтә алмый, тизрәк икенчесенә үрелә. "Сөннәт эшне торгызалар, имеш. Өстеңә гаиләңнең рәнҗешен алып, Раббыңның ризалыгына ирешеп булмас. Кайвакыт егетләрнең икенче хатын сәбәпле беренче гаиләләре җимерелә. Бу да бик аяныч хәл. Сиңа ничә бала тапкан, күпме хезмәт иткән хатыныңны гозерсез аерылу мөселман эше түгел. Ир кешегә икенче хатын алу мәҗбүри түгел, әмма беренче гаиләсен кайгырту, саклау изге бурыч булып тора. Ирләр бу мөһим нәрсәне онытмасалар иде. Әлбәттә, кайбер гаиләләрдә проблемалар күптән җыелып килгән була. Анда инде икенче хатынны: "Менә син генә безне аердың", - дип гаепләү гаделлек булмас. Гомумән, ир-егетләребезгә икенче хатынга күз ташлар алдыннан, җиде түгел, җитмеш мәртәбә үлчәргә кирәк.

Озын сүзнең кыскасы, күп хатынлылык мәсьәләсендә күп бәхәсләшергә, әллә нинди генә каршылыклы фикерләр тупларга була, әмма: этләр өрә, кәрван алга бара. Замана таләбе барыбер үзенекен ала. Бүген ир затларыбызны югалтып барабыз бит, җәмәгать. Дөньяга тигез санда килсәләр дә, ахырдан ирләр кими төшә. Өстәвенә күпмеләренә шешәдән башкасы кирәкми. Рәсәйдә генә 600 меңгә якын кеше төрмәдә утыра, күпчелеге ирләр. Күпме "ирләр" бүген үз ихтыяҗларын үз араларында гына хәл итүне өстен күрә. Андыйлар да, минемчә, чын ата күрмәгән, ата кулы тимәгән гаиләләрдән чыга. Муенына гаилә йөгәне киеп, гаилә арбасын тартырга теләүче чын ирләр аз калып бара. Калган хатын-кызларга яки ган ханымнарыбызның күбесе икенче, хәтта өченче хатынлыкка да ризалар. Әмма ирен көн саен күрергә өйрәнгән ханымнарның байлыклары белән бүлешәселәре килми. Тик тормыш дигәне шулай, берәүнең дә гомере буе ир куенында гына яшәячәгенә гарантия юк. Аллаһ сакласын, иртәгә үзе дә шул хәлдә калырга мөмкин.

Әгәр сау-сәламәт булган, хәленнән килгән, җаваплылыктан куркучы ир, ялгызлыктан иза чиккән бер хатынны алып, никахлашып, аны тәрбияле итсә, үз аталары да карамаган балаларын ашатып, тәрбияләп яши алса, андый ирне гаепләү түгел, түшенә медаль тагарга кирәк. Аны салым түләүдән азат итәргә, аңа "за ведность" түләргә кирәк. Чөнки, ул ир үз халкының, үз иленең чын каһарманы. Малайзия хөкүмәте икенче гаилә алып, ике гаиләне кайгыртканы өчен ирләргә пособие түләргә дигән карар чыгарды әнә.

Күп хатынлылык бүген безгә кирәкме, юкмы дигән сорауга төгәл җавап бирмим. Кемгәдер кирәк, кемгәдер хәерле, кемгәдер хәрам. "Син дә, гаиләң дә бу нәрсәгә әзер түгел. Булган гаиләңне җимерергә мөкинсең", - дип күп кенә егетләрне әлеге фикердән кайтарырга туры килде. Күп хатынлылык беркайчан да күпчелекнең насыйбы булмады. Элек тә татарның хәлле булганнары икенче хатын алган, икенчеләре бер хатыны булганга сөенеп яшәгән. Безгә дә, Аллаһы тәгалә бер хатын биргәнгә шөкер кылып, аларның кадерен белеп яшәүләрне насыйп итсен.

Күп балалы,
әмма бер хатынлы
***Йосыф хәзрәт ДӘҮЛӘТШИН***

# АК АЛТЫН ҖЫЙГАН ӘНИЕМ

**Совет чорында күпләре көньяк илләренә безнең төбәкләрдән бәхет эзләп никадәр халык күченеп китте?! Күпләре ул вакытта шул эссе якларга ияләшеп яшәргә дә калды. Яхшы, рәхәт тормышка кызыгу адәмне кайларда гына йөртми дә, кемнәр белән генә очраштырмый шул. Ләкин китүчеләр арасында нужалар килеп чыгу сәбәпле дә туган җирләреннән аерылучылар була. Шундыйларга минем әни дә керә. Моннан 30 еллар элек бер күрмәгән, белмәгән якларда берникадәр вакыт яшәп алган татар хатынының күңелендә ниләр булганын, кадерле укучылар, сезгә дә әни теле белән бәян итәргә булдым. Әни сөйли...**



...Акрын гына поезд тыкылдый. Юлы бик озын: Бөгелмә - Оренбург - Ташкент - Ашхабад. Шәһәр вокзалларына туктаган саен берәүләр чыга, икенчеләр керә.

Туган илдән җиде ят җиргә чыгып китү юктан гына булмады. Авыл "перспективасыз" дип табылгач та, яшь гаиләгә өй салып керергә рөхсәт бирмәделәр. Югыйсә төзелеш материаллары да әзер иде.

Озын юлга чыгарга әзерләнә башлагач та әбиең күп нәрсәләрне алдан сизенгәндәй тын гына йөрде. Аннары: "Кызым, юлга мәтрүшкә, кечкенә генә булса да каен пиннеге һәм шырпы кабына салып туган авылыбызның туфрагын ал. Алар бәла-казалардан саклар, ялгыз калганда күңелне юатыр, авырлыклар килгәндә җиңәргә көч бирер", - дип, үзе үк аларны хәстәрләп сумкага үк салып куйды. Әйберләре янында татар көйләре язылган пластинкага да урын табылды.

Биш тәүлек буена поезд тәрәзәсеннән карап бара торгач, Ашхабадка якынлаштык, СССРның иң көньяк ноктасы, иң кызу җире саналган Кушка шәһәренә дә килеп җиттек. Август азагы, шуңа карамастан, 50 градус эсселек. Ә башта төрле уйлар... Эссегә ничек түзәргә? Мондагы телне өйрәнеп, укытып булырмы? Чит халык кабул итәрме? Мең төрле уй эчендә янып, Теджен шәһәренә урнаштык. 25 нче урта мәктәптә укыта башладым.

Менә укытучыларның беренче профсоюз җыелышы буласы көн дә килеп җитте. Күпләр анда дулкынланып чыгыш ясады. Мин аларны игътибар белән тыңладым, ләкин барыбер берни дә аңламадым. Шунда түземлегем бетте һәм: "Авызыңны ачып бернәрсә аңламый утыр инде", - дип әйткәнемне сизми дә калдым. Шул вакыт мәктәп директоры Айлар Мәммедкурбанова бер укытучыдан үз телендә: "Ижмухамет ага, нәме кәплаер ол татар аялы (Ул татар хатыны нәрсә сөйли)?" - дип сорады. Әлеге укытучы аңа: "Мен һич зат төшенәмок (Мин бернәрсә дә аңламадым)", - дип әйтә диде. Минем эчемә җан керде. Бу мәктәптә туган телемне аңлаучы, белүче татар кешесе бар икән ләбаса! Җыелыштан чит җирдә ялгыз түгеллегемне тою хисе белән шатланып кайтып киттем.

Алга таба да мин монда татарларны шактый очраттым. Аларны җирле халык чиста, эшкә уңган булганнары өчен хөрмәт итә иде. Ә татарларның күбесе төрекмәнчә, казахча, үзбәкчә сөйләшергә өйрәнгәннәр. Татар кешесе нинди генә телне, гореф-гадәтләрне үзләштермәгән, нинди генә тормышка яраклашмаган! Җирле халык кебек татар хатыннары урамда, йомры мичтә нан (ипи) да пешерергә өйрәнгәннәр, 40-50 градус эсседә бозылмый, суытыкча куймыйча да саклап була торган, ашап туймаслык куырма да әзерлиләр. Өйгә кергән һәрбер кешене үз икмәкләре, үз куырмасы, үз сөзмәсе белән сыйлап та чыгаралар. Төрекмән киленнәре кебек күз явын алырлык итеп чигә, тегә, бәйли, келәмнәр тукый да беләләр. Без, татар хатыннары, бер атнада беребезгә, икенчесендә башкабызга җыелып утыра идек. Туган яклар, туганнар, дуслар турында сөйләшеп, хәл белешеп яшәдек.

Мамыкны утау, җыйнау вакытында ник бер җан иясе өйдә утырсын! Монда мамыкны "ак алтын" дип атыйлар. Урамнарда "Сән бугун канча пачта тиерден?" дигән язулар эленеп тора. "Син бүген күпме мамык җыйдың?" - дигәнне аңлата бу. Безнең татарлар да бу эшкә кулларыннан килгән кадәр ярдәм итәләр. Әлбәттә, икеләтә авырга туры килә, чөнки җирле халык кебек барыбер кызуга күнегеп бетеп булмый иде.

Ул дәвердә берәү берәүдән курыкмый иде. Коймалар да юк, күп кеше ишегалдында тапчанда, өстенә марля капланган сәке кебек урында йоклый.

Башта миңа аптырап карадылар. Күлмәгем дә кыска, башымда яулык та юк... Төрекмән хатыннары бик матур озын күлмәктән, башларына юка шәл ябып, аякларына ак туфли киеп йөриләр. Кайбер вакытта аларга карап еракта калган озын, бәби итәкле күлмәк кигән әнине искә төшерә идем. Анныры үземнең дә мондагы хатыннардан аерылып торасым килмәде. Киенү белән генә чикләнми, акрынлап төрекмән, үзбәк, таҗик телләренә өйрәндем. Рус



сыйныфын гына түгел, төрекмән балаларын да укыта башладым.

Беренче тәрбия сәгатен уздырганда мәктәпкә авылдан алып килгән пластинканы алып бардым. Укучыларым татар җырларын тын да алмыйча тыңладылар. Ә татар кызлары Роза, Римманың күңелләре тулды хәтта. Җыр бетүгә балалар бер-бер артлы сораулар яудырырга керештеләр. "Туган тел" белән башланган тәрбия сәгате мине укучыларыма якынайтты, арага җылылык иңдерде. Тора-бара ата-аналар, хезмәттәшләр үземә "мөгаллимә җан" дип эндәшә башлады.

Бервакыт без мотоцикл белән Иран чигенә таба йөрергә чыктык. Ниләр генә юк табигать кочагында! Эре-эре карбыз-кавыннарның иксезчиксез басулары... Кып-кызыл помидор, виноград, хөрмә үскән җирләрне күреп, оҗмах дип торасың! Теләгәнеңне күпме кирәк - җыеп ал, берәү дә сүз әйтми. Шунда ук 100 әр, 200 әр километрга сузылган, кеше аягы басмаган далалар, комлыклар, таулар... Ялгышканмын, далада да кеше яши икән. Кинәт кенә эт өргән тавыш ишетелде. Дала уртасында гаиләләре белән безнең тарафлардан күчеп килгәннәр яшәп ята! Җитмәсә хатыны безнең районнан - Актаныштан булып чыкты. Бу апаны күргәч күңел әчтән генә: "Эх дөнья, туганнардан, якыннардан аерып, бер кеше яшәмәгән дала уртасында көн күрергә син мәҗбүр итәсеңме?" - дип әрнеп куйды. Берникадәр вакыттан соң, туган яклары Чәчергә кайтып килгәч, әлеге апаны ире үтергәнен һәм балалары далада ятим калганын ишеттем...

Еш кына безнең татар икәнне белгәч: "Сез Казаннанмы?" - дип сорыйлар иде. Ә кайберләре: "Сез монгол татарымы?" - дип кызыксынды. Мин аларга: "Без мөселманнар", - дип җавап бирә идем.

Аягым белән көл сыман туфрак өстенә басып йөргәндә, күңелем туган ягым кырларына кайта, күземне йомсам - иген басуларын күргәндәй булам. Иранда, Памир таулары буенда үзенең каһәрле язмышы аркасында газиз иленнән-җиреннән аерылып, картайган көнендә баш төртер урыны булмаган татар әбиләре, бабайлары белән күрештем. Аларның да туган җирләрен чиксез сагынулары күзләрендәге моңсулыктан күренеп тора иде. Аларга карап тормыш алып бару никадәр авыр булса да, туган җиреңә кайтып, шунда яшәп картаю мең мәртәбә яхшырак икәнен аңладым, һәм укучыларым өйрәнеп бетергән "Туган тел" һәм башка татар җырлары пластинкасын, әнием киткәндә биргән бер уч туфракны алып, кайтыр юлга чыктым...

Әни гадәттә хатирәләрен барлаганда шушы урында туктап кала. Әмма моның белән генә бетми әле... Әни шул яклардан ияртеп кайткан гадәт буенча, без чәйне бала чакта пиаладан (касәдән) эчеп үстек. Ул хәзер дә чынаякка чәйне тутырып ясамый. Җылы якларда шулай кабул ителгән, хуҗа кеше чәйне аз-азлап өсти тора, ихтирамын күрсәтә тора. Шул якларның истәлеге булган шактый зур керәч чәчәкле чәйнеген әни күптән түгел миңа бүләк итте. Әлеге 40 яшьлек чәйнек эчендә Төрекмәнстанның Теджен районы Башкарма комитеты 1970 елда СССР Югары советы исеменнән тапшырган "В.И. Ленинның 100 еллыгы" медале саклана. Әнинең әлеге медальне тагып йөргән хәтерләмим дә. Күрәсең, аңар Ленин башлы бүләкнең үзе түгел, ә чит җирдә кыска гына вакытта күрсәткән хезмәтен зурлаулары кыйммәт. Ул чакларда бик тә зур бүләк саналган медальне кемгә бирү турындагы мәсьәлә укытучыларның профсоюз җыелышында тикшерелә. Җыелышта профсоюз оешмасы рәисе Кылычдурдый: "Татар хатыны берике ел эшләр дә китәр, төрекмән хатынына бирергә кирәк", - дигән фикерен әйтә. Шунда мәктәп директоры, ун бала анасы, үзе дә төрекмән хатыны Айлар Мәметкурбанова: "Бер татар аялын ун тәркмән аялына бирчеккәл", - дигән. Ягъни, "бер татар хатынын ун төрекмән хатынына алыштырмыйм". Әнине хезмәттәшләре туган ягына юл тотканда тандырда (ишегалдындагы йомры мич) пешкән биш йомры ипи һәм киез чәчкәле палас бүләк итеп озатып калганнар.

*Айзирәк ГӘРӘЕВА*

## Үзбәкстан мөселманнары рухи лидерлары белән хушлашты

Үзбәкстан мөселманнары март аенда зур югалту кичерде. Олуг галим, күпләрнең рухи остазы, Үзбәкстанның элеккеге мөфтие Мөхәммәд Садыйк Мөхәммәд Йосыф вафат булды. Җеназа намазы Ташкентның Шәех Зәйнетдин мәчетендә укылды. Аның белән бәхилләшергә йөз меңнәрчә мөселман килгән иде. Милиция хезмәткәрләренә хәтта мәчет яныннан уза торган юлларны ябып торырга туры килгән.



## Мәккәдән Мәдинәгә 30 минут эчендә

Җиддә, Мәккә һәм Мәдинәне тоташтырачак тизйөрешле тимер юл төзелеше инде моннан дүрт ел элек үк башланган иде. Бу - миллионнарча мөселманнарның хаҗ гамәлләре кылуын һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәдинәдәге мәчетенә баруын җиңеләйтүне күздә тотып башланган проект. Беренче поезд 2012 елда ук кузгалырга тиеш булса да, эш һаман сузыла, чөнки проектны тормышка ашыруны үс өстенә алган Испания фирмасына ... гарәп чүлләре каршылык күрсәтә икән. Тимер юлны төзүчеләр 300 км сәгать тизлектә очып килүче поездның юлына ком бархannары киртә булыр дип башларына да китермәгәннәр. Хәзер алар юлның 110 чакрым өлешендә рельсларны ком буранныннан саклар өчен 5 метрлы диварлар корырга уйлыйлар.



## Мисырлы Мөхәммәд Сәлләм Марска очарга җыена

Бу аның балачак хыялы икән. Әмма ул чынлыкта Кызыл планетада яшәргә туры килер дип уйламаган. Голландиянең Mars One дип аталган компаниясе 2025 елда 50 хатын-кыз һәм 50 ир-атны Марска озатырга җыена. Менә шул исемлеккә Сәлләм дә эләккән. "Мин кечкенәдән астронавт булырга хыялландым, астрономия белән кызыксынам, планеталарны өйрәнәм. Марска үзем белән Мисыр флагын, Коръән һәм пианино алырга җыенам, -ди Мөхәммәд Сәлләм. - Мин бертуган энекәшем белән генә яшим, әти-әнием вафатлар. Шунлыктан чит планетага бөтенләйгә күчеп китү миңа авыр булмаячак", - дип фаразлый ул.



## Дубай сәүдә фестиваленә килгән туристлар ислам динен кабул итә

Дубайда үткән быелгы сәүдә фестивалендә дә дистәләгән туристлар ислам динен кабул иткән. "2015 елга стратегик планнар кысаларында, без сәүдә һәм туризмны исламның төп кыйммәтләрен яктыртуда файдаланабыз һәм ислам турында җәмгыятьтә таралган ялгыш фикерләрне төзәтергә тырышабыз", - ди илнең Ислам һәм хәйрия эшләре буенча департамент рәисе Худа әл Кааби. Департамент мәгълүматлары буенча, быел гыйнвар аенда үткән сәүдә фестивалендә 53 кеше ислам кабул иткән. Яңа мөселманнар AlReef дип аталган динара программада катнашканнар, дискуссияләр, лекцияләр аша ислам дине, күпгасырлык ислам культурасы турында белемнәрен арттырганнар.



## Германиядә беренче мөселман зираты ачарга җыеналар

Вупперталь шәһәре хакимияте Германиядә беренче мөселман зираты ачарга планлаштыра. Яңа зиратка тәгаенләнгән җир кишәрлеге элек протестант чиркәве карамагында булган. Тиздән ул мөселман җәмгыятенә тапшырылачак. Протестантлар һәм мөселманнарныкы янәшәсендә яһүдләр зираты да бар. Төньяк Рейн-Вестфалиянең Ислам кануннары буенча җирләү институты директоры Хишам әл-Фоунти (Hisham El-Founti) болай дип белдергән: "Мөселманнарның аерым зиратлары булу - бик мөһим нәрсә. Димәк, мөселманнар ислам кануннары буенча җирләнә башлаячак. Моңа кадәр без дин кардәшләребезне җирле зиратларда бер читтәрәк җирли идек".



## Миллионнарча бала Сүрия һәм Гыйрактагы чуалышлар корбанына әверелде

БМОның Балалар фонды, Сүриядә һәм Гыйракта барган чуалышлар нәтиҗәсендә 14 000 000 баланың язмышы куркыныч астында, дип белдерде.

Фонд мәгълүматларына караганда, бүгенге көндә 5 600 000 нән артык сүрияле бала үз илендә җәфа чигә, 2 000 000 нан артыгы качак хәлендә Ливан, Төркия, Иордания һәм башка дәүләтләрдә яши. 2 800 000 нән артык гыйраклы бала туган җирләрен ташлап киткән, байтагы хәрби төркемнәр карамагындагы, сугыш барган районнарда калган. Экстремистик "Ислам дәүләте" территориясендәге 12 яшьлек һәм аннан өлкәнрәк балаларны хәрби хәзерлек үтәргә, терактларда һәм үтерүләрдә катнашырга мәҗбүр итәләр.



## "Азан" радиосында солдат хатлары яңгырый




Бөек Җиңүнең 70 еллыгы якынлашканда "Азан" радиосы махсус проект әзерләде. "Письма одного солдата" - ("Солдат хатлары") дип аталган тапшыру туры эфирда чыга һәм һәр тапшыруда Бөек Ватан сугышы каһарманнарының сәлам хатлары укыла. Сугыш кырларын узып, туган җирләргә кайтып җиткән хатларда солдат сүзләре, уйлары, теләкләре сакланган.

Хатлар Татарстан Милли музееннан алынды.

Тапшыру һәр атнаның дүшәмбе һәм чәршәмбе көннәрендә сәгать 8.50, 12.50 һәм 20.50 дә эфирга чыга. Шулай ук тапшыруларның аудиоязмаларын радионың ***"В Контакте"дагы төркемендә (https://vk.com/radioazan)*** кереп тыңларга мөмкин.

## НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Таң беленә башлый | Мәчетләрдә укыла | Кояш чыга | Өйлә Намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ясту намазы | Кыбла |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.04.2015 | 03:01 | 03:45 | 05:15 | 11:47 | 16:11 | 18:20 | 20:09 | 12:35 |
| 02.04.2015 | 02:58 | 03:43 | 05:13 | 11:47 | 16:12 | 18:22 | 20:11 | 12:34 |
| 03.04.2015 | 02:54 | 03:40 | 05:10 | 11:46 | 16:14 | 18:24 | 20:14 | 12:34 |
| 04.04.2015 | 02:51 | 03:37 | 05:07 | 11:46 | 16:15 | 18:26 | 20:17 | 12:33 |
| 05.04.2015 | 02:47 | 03:35 | 05:05 | 11:46 | 16:17 | 18:28 | 20:19 | 12:33 |
| 06.04.2015 | 02:44 | 03:32 | 05:02 | 11:46 | 16:18 | 18:30 | 20:22 | 12:32 |
| 07.04.2015 | 02:40 | 03:30 | 05:00 | 11:45 | 16:20 | 18:32 | 20:25 | 12:32 |
| 08.04.2015 | 02:36 | 03:27 | 04:57 | 11:45 | 16:21 | 18:34 | 20:28 | 12:31 |
| 09.04.2015 | 02:32 | 03:24 | 04:54 | 11:45 | 16:23 | 18:36 | 20:30 | 12:31 |
| 10.04.2015 | 02:29 | 03:22 | 04:52 | 11:44 | 16:24 | 18:38 | 20:33 | 12:30 |
| 11.04.2015 | 02:25 | 03:19 | 04:49 | 11:44 | 16:25 | 18:40 | 20:36 | 12:30 |
| 12.04.2015 | 02:21 | 03:17 | 04:47 | 11:44 | 16:27 | 18:42 | 20:39 | 12:29 |
| 13.04.2015 | 02:17 | 03:14 | 04:44 | 11:44 | 16:28 | 18:44 | 20:42 | 12:29 |
| 14.04.2015 | 02:13 | 03:12 | 04:42 | 11:43 | 16:30 | 18:46 | 20:45 | 12:28 |
| 15.04.2015 | 02:09 | 03:09 | 04:39 | 11:43 | 16:31 | 18:48 | 20:48 | 12:28 |
| 16.04.2015 | 02:05 | 03:07 | 04:37 | 11:43 | 16:32 | 18:50 | 20:51 | 12:27 |
| 17.04.2015 | 02:00 | 03:04 | 04:34 | 11:43 | 16:34 | 18:52 | 20:54 | 12:27 |
| 18.04.2015 | 01:56 | 03:02 | 04:32 | 11:42 | 16:35 | 18:54 | 20:57 | 12:27 |
| 19.04.2015 | 01:52 | 02:59 | 04:29 | 11:42 | 16:36 | 18:56 | 21:01 | 12:26 |
| 20.04.2015 | 01:47 | 02:57 | 04:27 | 11:42 | 16:38 | 18:58 | 21:04 | 12:26 |
| 21.04.2015 | 01:43 | 02:54 | 04:24 | 11:42 | 16:39 | 19:00 | 21:07 | 12:25 |
| 22.04.2015 | 01:38 | 02:52 | 04:22 | 11:42 | 16:40 | 19:03 | 21:11 | 12:25 |
| 23.04.2015 | 01:33 | 02:50 | 04:20 | 11:41 | 16:42 | 19:05 | 21:14 | 12:24 |
| 24.04.2015 | 01:28 | 02:47 | 04:17 | 11:41 | 16:43 | 19:07 | 21:17 | 12:24 |
| 25.04.2015 | 01:23 | 02:45 | 04:15 | 11:41 | 16:44 | 19:09 | 21:21 | 12:24 |
| 26.04.2015 | 01:17 | 02:43 | 04:13 | 11:41 | 16:45 | 19:11 | 21:25 | 12:23 |
| 27.04.2015 | 01:12 | 02:40 | 04:10 | 11:41 | 16:47 | 19:13 | 21:28 | 12:23 |
| 28.04.2015 | 01:06 | 02:38 | 04:08 | 11:41 | 16:48 | 19:15 | 21:32 | 12:23 |
| 29.04.2015 | 01:00 | 02:36 | 04:06 | 11:40 | 16:49 | 19:17 | 21:36 | 12:22 |
| 30.04.2015 | 00:53 | 02:33 | 04:03 | 11:40 | 16:50 | 19:19 | 21:40 | 12:22 |

## "ӨЧЕСЕ, ҖИДЕСЕ, КЫРЫГЫ"...

"Хузур" нәшрият йорты ислам диненең төрле сорауларын кыскача аңлаткан һәм кулланырга уңайлы кечкенә брошюралар чыгаруны дәвам итә. Чираттагысы "Өчесе, җидесе, кырыгы" дигән исем белән дөнья күрде. Анда сүз мәрхүмнәрне өченче, җиденче, кырыгынчы көнендә искә алу, алар рухына багышлап догалар уку турында бара.




Габдулла хәзрәт Әдһәмов хәнәфи мәзһәбе өйрәтүләренә таянып, әлеге дини йолаларның рөхсәт ителгәнлегенә 7 дәлил китерә.

**По вопросам рекламы обращаться по телефону (843) 253-60-52**

# "ЗӘКЯТ" АКЧАСЫ НИНДИ МАКСАТКА ТОТЫЛА?

**Әссәләәмү галәйкүм, хөрмәтле мөселман кардәшләр!**

Минем сезгә "Зәкят" хәйрия фондының эшчәнлеге, ике ел эчендә ирешкән уңышлары һәм алдагы планнары турында сөйлисем килә.

Безнең команда 2013 елның июнь аенда эшли башлады. Алдыбызда торган беренче мәсьәлә - фондка зәкят түләүчеләрнең ышанычын яулау һәм мөселманнарга вакытында зәкят түләүнең мөһимлеген җиткерү иде. Шул максатны күз алдында тотып, без зәкятрт.ру сайтын гамәлгә керттек. Анда ай саен мөселманнар алдында кергән һәм тотылган акчалар буенча җентекләп хисап бирәбез.

Зәкят акчаларын без аерым җыябыз һәм таратабыз. Ул акчалар мескен, фәкыйрь, гарип һәм мосафирларга, кыен хәлдә калучыларга, Аллаһы тәгалә юлында булучыларга һәм зәкят җыючыларга бирелә.

Сәдака шулай ук мохтаҗларга таратыла, моннан тыш, төрле чаралар, Коръән уку буенча конкурслар, викториналар үткәрелә, гарип һәм ятим балаларга ислам дине турында сөйләү максаты белән чәй табыннары оештырыла, мәчетләр төзелә.

Ике ел эчендә 8 000 000 сумнан артык зәкят һәм сәдака җыеп тараттылды.




Безнең сайтта "Кем ярдәмгә мохтаҗ" бүлегендә мөрәҗәгать иткән кешеләрнең кыскача характеристикасы бирелгән таблица урнаштырылган. Бу - зәкят түләргә яки сәдака бирергә ниятләгән мөселман үзе теләгән кешегә ярдәм күрсәтә алсын өчен эшләнде. Шулай итеп, узган ел 500 кешегә ярдәм күрсәтелде.

"Мөгаллим" дип аталган проектны 2014 елның сентябрь аенда республиканың берничә районында һәм Казан мәчетләрендә гамәлгә керттек - олыларны һәм балаларны Коръән укырга өйрәтү өчен мөгаллимнәр җибәрелде. Бүгенге көндә 24 мәчеттә 30 мөгаллим эшли. Мәчеткә килергә мөмкинлекләре булмаган авыру, гарип, башка шәһәрләрдән булган кешеләр скайп аша белем ала. "Зәкят" фонды һәр мөгаллимгә эш көне исәбеннән хезмәт хакын түли.

Тагын бер проектыбызның максаты - мәктәп яшендәге балаларны ислам динен өйрәтү өчен мәчетләргә җәлеп итү. Бу максат белән без Казанда һәм республикада ислам дине белемәнә викториналар уздырабыз. Иң яхшылары фонд бүләкли. Бүгенге көндә викториналар республиканың күпчелек районнарында үткәрелде, без бу эшне дәвам итәбез, уку елы ахырында Болгар шәһәренең Ак мәчетендә республикакүләм викторина һәм Коръән укучылар конкурсы оештырырга планлаштырабыз. Балалар өчен шундый ук зур конкурс һәм викторинаны 2014 елның май аенда да үткәргән идек. Бу чаралар матур гадәткә кереп китәр дип өметләнәбез.

2013 һәм 2014 елларда Корбан бәйрәмендә ТР мөселманнары Диния нәзарәте белән берлектә Теләче районында ятим инвалид балалар приюты төзелешенә акча җыю өчен телемарафон оештырылды. 1 850 000 сум акча приют счётына күчерелде.

Зәкятнең мөһимлеген аңлаган дин кардәшләребездән Аллаһ рәббыбыз разый булсын, алга таба да һәммәбезгә саваплы гамәлләр кылып яшәргә язса иде.

***Илнур хәзрәт ВӘЛИЕВ,***
***"Зәкят" хәйрия фонды генераль директоры***

## "Коръән – һәр йортка" акциясе дәвам итә



Россия ислам институты узган елның декабрь аенда "Коръән - һәр йортка" дигән гадәти булмаган акция оештырган иде. Акция кабат башлана. Март ае дәвамында РИИ студентлары һәм хәзрәтләр өйгә килеп, азан әйтә, Коръән укый, шул рәвешле, өйне рухи сафландыра. Йортка азан әйтү, бәрәкәтле догалар уку саваплы гамәл. Моннан тыш өйгә килгән дин әһелләре дингә кагылышлы сорауларга җавап бирергә дә әзер.

**Акция түләүсез.** Ай дәвамында түбәндәге номерга шалтыратырга һәм хәзрәтләрне өйгә чакырырга мөмкин: **8-950-313-33-01, 8-927-242-35-78.**

## ТАТАР ШӘМАИЛЕ КОНКУРСЫНДА БАЛАЛАР ДА КАТНАША



*Мәгълүм булганча, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте шәмаилләргә бәйле традицияләрне саклау һәм ныгыту максатыннан шәмаилләр конкурсы игълан итте. Татар шәмаиле конкурсы ТР МДН оештырган "Минем өемнең шамаиле" республика акциясе кысаларында үткәрелә.*

*Әлеге конкурста балалар да катнаша ала. Конкурста катнашырга теләүче балалар нәзарәткә үзләренең эшләрен җибәрә башладылар инде.*

*Чаллыдан 11 яшьлек Регина Бәдертдинова да шәмаилләр ясау белән мавыга икән. Беренче шәмаилен ул 9 яшендә ясаган. Регина шәмаилләрен туганнарына, дусларына, әби-бабайларына бүләккә бирү өчен, аларны сөенсеннәр өчен ясый. Бу һөнәргә аны укытучы Гөлшат апасы өйрәткән. Күптән түгел Чаллының Муллануp Вахитов исемендәге 2нче татар гимназиясендә булып үткән хәйрия ярминкәсендә 3 шәмаилен сатып, акчасын балалар йортына җибәргәннәр.*

***Конкурс турында тулырак мәгълүмат dumrt.ru сайтында.***

ДИН вә МӘГЫЙШӘТ
*Март саны, № 3 (236)*

**Мөхәррир:** Нәүбәһар КӘБИРОВА
**Дизайнер:** Гүзәл МИҢНУЛЛИНА
**Корректор:** Айгөл КРОХИНА
Газета логотибы **хәттат** Рамил НАСЫЙБУЛЛОВ тарафыннан эшләнде

**Редакция советы:**
*Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе* ***Камил СӘМИГУЛЛИН;***
*"Хузур" нәшрият йорты директоры* ***Ришат ХӘМИДУЛЛИН;***
*ТҖМДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе* ***Нияз САБИРОВ;***
*Татарстанның баш казые* ***Җәлил ФАЗЛЫЕВ;***
*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе* ***Габдулла ӘДһӘМОВ.***

**Гамәлгә куючы:** *Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27).*
**Нәшир:** *"Хузур" нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в)*

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:** *420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27/*
**Электрон адрес:** *naubahar67@list.ru.*
**Телефон:** *+7 950 326 38 36*

**Язылу индексы: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин**

*Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.*
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета **"Татмедиа" ААҖ филиалы - "Идел-Пресс"** полиграфия-нәшрият комплексында басылды *(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2).*
**Тираж: 5 мең данә** Заказ **№ 9053**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - **6 сум.**
График буенча бу санга **25 нче март** көнне **18.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде.
Кул куелды: **18.00 сәгатьтә.**